ДУСЛАР ОЧРАШУЫ

Казанда Үзбәкстан белән Россия арасын тагын да якынайту турында сөйләшүләр

> 2

МАЛЛАР ДА ЕЛЫЙ

«ВТ» хәбәрчесе Яңа Чишмә районындагы фермаларның ябылу сәбәбен ачыкларга тырышты

> 5

РӨСТӘМ ЗАКИРОВ:

«Әнинең яраннары – әле дә өй түрендә»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 146 (29113) | Җомга | 6 октябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ru.freepik.com

ЧИР ЧИТЛЕГЕНДӘ

ВИРУСЛЫ ЧИРЛӘР КОТЫРГАН ЧОРДА СӘЛАМӘТЛЕКНЕ НИЧЕК САКЛАРГА?

«Чирләп киттем әле». Соңгы арада, кемгә сүз катма, шулай ди. Бер караганда, эссе җәйдән шундук салкын көзгә атламадык та кебек: сентябрь җылысын мулдан бирде. Шуңа да карамастан чир чигенмәде, көзнең беренче айларында салкын тию, шул исәптән коронавирус белән дә ешрак авырый башладык. Вируслы чирләр котырганда сәламәтлекне ничек кайгыртырга? Вакцина ясатыргамы, юкмы? «ВТ» хәбәрчесе белгечләр белән шул сорауларга җавап эзләде.

> 6–7

Ишетми калмагыз

Республикада «Мәшгульлеккә ярдәм итү» федераль проекты гамәлгә ашырыла башлады. Аның буенча 24 районның 65 мәгариф оешмасында 1,3 мең кеше яңа һөнәргә бушлай өйрәнә алачак.
Проектта 50 яшьтән өлкәнрәкләр, эшсез яки эштән җибәрелү куркынычы янаган кешеләр, 3 яшькә кадәр бала карау ялындагы аналар, 7 яшькә кадәр балалары булган аналар катнашырга мөмкин. Моннан тыш армиядән соң яки белгечлек алганнан соң 4 айдан күбрәк эш таба алмыйча йөрүче 35 яшькә кадәрге кешеләр яңа һөнәр үзләштерә алачак. Шулай ук махсус хәрби операция ветераннары һәм һәлак булганнарның гаиләләре әгъзалары да бушлай белем алырга чакырыла.

Сентябрь аенда Татарстанда талпан кадалу очраклары августтагы белән чагыштырганда ике тапкыр арткан. Роспотребнадзорның матбугат хезмәте хәбәренә караганда, августта 861 кеше табибларга мөрәҗәгать итсә, узган айда бу сан 1,8 меңгә җиткән. Ведомство белгечләре аңлатып үткәнчә, талпаннар апрельдән октябрь аена кадәр актив. Сентябрьдә ныграк котырулары исә кышны җиңелрәк кичерү өчен күбрәк «май» җыеп калырга тырышуларына бәйле. Быел яздан бирле Татарстан хастаханәләренә, талпан кадалу сәбәпле, барлыгы 9,8 мең кеше мөрәҗәгать иткән инде. Узган ел 9,6 мең очрак теркәлгән.

Ноябрь бәйрәмнәрендә Казанга өстәмә поездлар җибәреләчәк. Казан мэриясе сайты хәбәр иткәнчә, «Россия тимер юллары» Санкт-Петербург белән Казан, Воронеж белән Казан арасында йөрүче поездлар санын арттыра. Быел бәйрәм көннәре 4–6 ноябрьгә туры килә. Сүз уңаеннан, Казан белән Ульяновск арасында өстәмә электр поездлары йөри башлаган. 14 сентябрьдән «электричка» Казаннан Ульяновскига пәнҗешәмбе, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәрендә китә. Ә кире юнәлештә – җомга, шимбә, якшәмбе һәм дүшәмбе көннәрендә.

Атна ахырына таба Татарстанда, төньяктан циклон үтеп керү сәбәпле, һава торышында кискен үзгәрешләр көтелә. Якшәмбе – 8 октябрь һәм дүшәмбе – 9 октябрьдә кайбер районнарда юеш кар явып үтәргә мөмкин. Якшәмбе көнне җил көчәя: секундына 15–20 метрга, урыны белән 24 метрга җитәчәк. Шимбә – 7 октябрьдә көндез һава температурасы +9…+14 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә +4…+9 градус. Якшәмбе – 8 октябрьдә көндез термометрның терекөмеш баганасы +6…+12 градуска кадәр генә күтәреләчәк. Төнлә +1…+5 градус булачак. Дүшәмбе – 9 октябрьдә көндез +3…+8 градус. Сишәмбе – 10 октябрьдә төнлә суыта: һава температурасы +2…–1 градус тәшкил итәчәк. Көндезге температураның да +3…+8 градустан артмавы көтелә. Кайбер районнарда явым-төшем булачак.

ХЫЯЛЛАР ЧЫНГА АШКАНДА

Үзбәкстанга Татарстан аша якынрак. Башкалада бу көннәрдә Үзбәкстан белән Россия арасын тагын да якынайту турында сөйләштеләр. Казанга Үзбәкстан Президенты Шәүкәт Мирзиёев та килде. Ул үзенең Татарстанга сәфәрен «хыялының чынга ашуы» дип бәяләде. Аерым алганда, Үзбәкстан белән Татарстанны нәрсә бәйли? «Россия – Үзбәкстан төбәкара хезмәттәшлек форумы»нда кем һәм нәрсә белән үзенә җәлеп итәргә тырышты?

tatarstan.ru

Шәүкәт Мирзиёевның Татарстанга беренче тапкыр килүе. Моны чын мәгънәсендә тарихи вакыйга буларак бәяләргә мөмкин. Ул форум кысасында тәкъдим ителгән күргәзмәне дә карады. Гомумән, эшлекле форумга нәтиҗәне дә алар Рәис белән бергә ясады.
Шәүкәт Мирзиёевка нәрсә күрсәттеләр соң?
Әйтик, Казан вертолет заводы «Ансат» вертолетын тәкъдим итте. Ул махсус медицина бурычларын үтәү өчен җиһазландырылган. «Ансат»ларны медицина эвакуациясе өчен бөтен ил буенча кулланалар. Санитар авиация карамагында 28 шундый вертолет бар.
КАМАЗ исә трактор, узбушаткыч, электробус, «КАМАЗ-Мастер» командасының спорт йөк машинасын тәкъдим итте.

Вәгъдә үтәлде

Шәүкәт Мирзиёев Казанны күптәннән күрергә теләгән икән. Форум узганнан соң Казан Кремлендә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән очрашуда ул бу хакта да искәртте һәм хыялының чынга ашуын әйтте.

– Җылы кабул итүегез өчен рәхмәт. Очрашкан саен, Татарстанга киләм, дип вәгъдә итә идем. Бүген биредә сезнең җитәкчелек итү нәтиҗәләрен, үзгәрешләрне үз күзләрем белән күрдем, – диде тугандаш республика җитәкчесе.

Рөстәм Миңнеханов та рәхмәтле Үзбәкстан Президентына.

– Форум өчен рәхмәт. Ул югары дәрәҗәдә узды. Бүген без гамәлгә ашыра торган проектлар эре сәнәгать предприятиеләрен генә түгел, кече һәм урта бизнесны да үз эченә ала, – дип искәртте очрашуда Рөстәм Миңнеханов. – Сезнең миңа карата шәхси мөнәсәбәтегезне бик кадерлим. Сез һәрвакыт безнең проектларга булышасыз. Үзбәкстанда яшәүче ватандашларыбызга ярдәм иткәнегез өчен аерым рәхмәт!

Ул билгеләп үткәнчә, ике республика делегациясе актив эшли, моны Казанда форумның уңышлы узуы дәлилли. Моннан тыш, Президент Үзбәкстанда татар диаспорасының активлыгын билгеләп үтте.

– Мин алар белән вакыт-вакыт очрашам, һәм алар һәрвакыт Татарстан турында, сезнең хакта горурлык белән сөйлиләр, – диде Үзбәкстан Президенты.

Хезмәттәшлекнең яңа этабы

Эшлекле даирәләрдән 700ләп катнашучы, Россиянең 19 һәм Үзбәкстанның 12 төбәгеннән килгән кунаклар, күргәзмәдә – 70ләп компания. «Казан Экспо» күргәзмәләр үзәгендә «Россия – Үзбәкстан төбәкара хезмәттәшлек» форумының пленар утырышы хезмәттәшлек мөнәсәбәтләрен үстерү, яңа элемтәләр табу турында сөйләштеләр. Үзбәкстан вәкилләре – Россиягә, Россия Үзбәкстанга нәрсәсе белән кызыклы булуы хакында сөйләде. Сүз уңаеннан, бу форум өченче тапкыр уздырыла.

Үзбәкстан безгә ят түгел. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов сүзләре белән әйтсәк, ике халыкны да тел, дин, мәдәният ягыннан уртак җепләр бәйли. Үзбәкстанда татарлар да күп (300 меңләп), Татарстанда да ерак күршеләребез шактый. Соңгы елларда аралар тагын да якынаеп, икътисадый хезмәттәшлек тә ныгыган.

> **– Узган елгы нәтиҗәләр буенча ике республика арасында товар әйләнеше 50 процентка үсте һәм 290 млн доллардан артып китте. Агымдагы елның беренче яртыеллыгында үзара сәүдә күләме тагын 30 процентка артты, – дип санлы күрсәткечләр белән таныштырды Рәис.**

Күч тә, мөмкинлекләр дә күп, алга таба да төрле юнәлешләрдә хезмәттәшлекне үстерү ягын кайгыртачакбыз, ди Рөстәм Миңнеханов.

Пленар утырышта ике якның да төбәкләре җитәкчеләре сүз алды. Әйтик, Үзбәкстанның Җизак өлкәсе хәкиме Эрган Салиев Россияне төп икътисадый партнерларның берсе дип атады. Соңгы елларда авыл хуҗалыгы, сәнәгать, машина җитештерү юнәлешләре буенча эш алып барылганын әйтте.

– Үзбәкстан компанияләре дә Татарстандагы проектларга инвестиция кертә, – диде Ташкент өлкәсе хәкиме Зойир Мирзаев. – Әйтик, Казанда махсус үзәк булдыру турында килешү имзаладык. Ул яшелчә, сөт һәм башка фермер продукциясен саклау, эшкәртү, төрү һәм сатуга чыгару белән шөгыльләнәчәк. Авыл хуҗалыгы продукциясен Үзбәкстаннан китерү күздә тотыла.

Безнекеләрдән Иваново өлкәсе губернаторы Станислав Воскресенский чыгыш ясады. Ул Үзбәкстан дусларыбызны онлайн сәүдәгә өйрәтә алабыз дип кызыктырды (баксаң, алар онлайн сәүдә буенча илдә Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан соң икенче урында тора икән). Җиңел сәнәгать юнәлешендә Үзбәкстан белән эшләүләрен әйтте.

Самара губернаторы Дмитрий Азаров автомобиль җитештерү мәсьәләсенә игътибар итте. Губернатор әйтүенчә, АвтоВАЗга бәйле проектны яңадан башлап җибәрергә кирәк. «АвтоВАЗ»ның үзбәк партнерлары белән сөйләшүләр нәтиҗәсендә якын арада «Lada» машинасын җыю һәм сату янә башланыр дип өметләнәбез», – диде ул.

Сүз уңаеннан

Үзбәкстанның тугандаш халкы теле, традицияләре, дине һәм рухы белән безгә якын. Безне күп нәрсә якынайта. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Каракалпакстан Республикасы (Үзбәкстан Республикасы) Жокаргы Кенесы (Югары Советы) Рәисе, Үзбәкстан Республикасы Сенаты башлыгы урынбасары Аманбай Орынбаев белән очрашуда шулай диде. Очрашу республика парламентында узды.

Очрашуда парламентчылар, Россия – Үзбәкстан хезмәттәшлеге, шул исәптән парламентара элемтәләр кысасында, Татарстан белән Каракалпакстан арасындагы күп яклы элемтәләрне киңәйтү мәсьәләләрен карады.

Фәрит Мөхәммәтшин Татарстанның күпмилләтле республика булуын, биредә 175 милләт вәкиленең үзара тынычлык-татулыкта яшәвен билгеләп үтте. 30 елдан артыграк вакыт дәвамында Татарстан Халыклары ассамблеясы уңышлы эшләп килә. Үзбәкләрнең милли-мәдәни автономиясе исә ассамблеяның иң зур, иң абруйлы һәм иң нык үсеп килүче җәмгыятьләреннән берсе булып тора, диде ул.

Аманбай Орынбаев, үз чиратында, республика җитәкчелегенә җылы кабул итүләре һәм форумны югары дәрәҗәдә оештырулары өчен рәхмәт белдерде.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

САН

- ✓2023 елның гыйнвар – июль аенда Россия белән Үзбәкстан арасында товар әйләнеше 5,5 млрд долларга җитте. 2022 ел нәтиҗәләре буенча товар әйләнеше 9,3 млрд доллар иде.
- ✓Россия Үзбәкстанның төп тышкы сәүдә партнеры санала (икенче урында – Кытай).
- ✓Форум кысасында ике як арасында 3 регионара һәм 7 коммерциячел килешү имзаланды. Бу килешүләр җитештерүнең төрле өлкәләренә бәйле.

8 октябрь – Авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү сәнәгате хезмәткәрләре көне

ҖИРГӘ ТУГРЫЛЫК

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат ҖӘББАРОВның бәйрәм КОТЛАВЫ

Сезне һөнәри бәйрәмебез – Авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү сәнәгате хезмәткәрләре көне белән чын күңелдән котлыйм!

Бу күркәм бәйрәмнең төп асылы – тормыш һәм хезмәт юлын авыл хуҗалыгына, халыкның тормыш дәрәҗәсен, сәламәтлеген һәм муллыгын арттыруга, илебезнең азык-төлек иминлеген ныгытуга багышлаган, ял һәм бәйрәм көннәре белән исәпләшмичә, көнне төнгә ялгап кыр-басуларда, фермаларда эшләүче авыл хезмәтчәннәренә, азык эшкәртү сәнәгате предприятиеләрендә армый-талмый эшләүче хезмәткәрләргә, гомумән, эшчәнлеге аграр тармакка бәйле булган һәркемгә хөрмәт күрсәтүдән гыйбарәт. Сезнең һәрберегезнең авыр һәм фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә республикабызның авыл хуҗалыгы һәрвакыт тотрыклы үсештә һәм без күп позицияләр буенча Россия күләмендә алдынгылар рәтендә барабыз. Агросәнәгать комплекслары һәм фермер хуҗалыклары гражданнарны экологик имин продуктлар белән тәэмин итү өчен даими рәвештә үзләренең җитештерүен арттыралар. Авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү сәнәгате бер-берсеннән аерылгысыз үсә, конкурентлыкка сәләтле продукция җитештерү өчен яңа алымнар, заманча технологияләр кулланалар. Көтмәгәндә, әмма ел саен килеп чыга торган төрле табигать сынауларына да карамастан, сез ирешкән казанышлар нигезендә, әлбәттә, хезмәт сөючәнлек, сайлаган һөнәрегезгә, эшегезгә тугрылыклы булып калу һәм туган җиргә мәхәббәт ята.

Кадерле кыр һәм ферма хезмәтчәннәре, агросервис, әзерләү һәм эшкәртү сәнәгате предприятиеләре хезмәткәрләре! Сезгә фидакарь хезмәтегез, ирешкән уңышларыгыз, туган җирне яратуыгыз һәм аңа тугрылыклы булып калуыгыз өчен олы рәхмәтемне белдерәм! Сезгә һәм сезнең якыннарыгызга нык сәламәтлек, тормышыгызда шатлык-куанычлар, Татарстан һәм илебез муллыгын арттыруда уңышлы хезмәт нәтиҗәләренә һәм югары күрсәткечләргә ирешүегезне телим!

АВЫЛ ЯШЬЛӘРЕ – ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Киров шәһәрендә Идел буе федераль округы субъектларының дәүләт хакимияте законнар чыгару (вәкиллекле) органнары ассоциациясе утырышында катнашты. Парламентчылар округ төбәкләрендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, авыл яшьләренә ярдәм итү һәм аларны ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү мәсьәләләрен карады.

Округ төбәкләрендә яшьләр сәясәтен тормышка ашыру һәм авыл яшьләренә ярдәм итү мәсьәләләре утырышта игътибар үзәгендә булды.

Яшьләр берләшмәләре лидерлары, агропредприятиеләр хезмәткәрләре, шулай ук авыл яшьләре белән эшләүгә юнәлдерелгән проектлар авторлары өч көн дәвамында авыл территорияләрен үстерү буенча тәкъдимнәр эшләде. Алар авыл киләчәге, агробизнесны нәтиҗәле үстерү һәм авыл җирендә яшәү шартларын шәһәрдәгедән ким булмаган дәрәҗәдә яхшырту турында сөйләштеләр.

– Авыл яшьләре слетында күтәрелгән проблемалар тулаем бөтен илгә кагыла, – диде Фәрит Мөхәммәтшин, егет-кызларга мөрәҗәгать итеп. – Инде хәзер сез билгеләгән бурычларны тормышка ашыру турында уйланырга кирәк. Хәзерге вакытта төбәкләр бюджетларын һәм җирле бюджетларны булдыру эше алып барыла. Бәлки, нindидер проектларны аларга инде хәзер үк кертергәдер? Шулай ук кайсыдыр мәсьәләләрне федераль дәрәҗәдә хәл итәргә кирәклеге турында уйлашырга кирәктер.

Идел буе төбәге закон чыгаручылары фикеренчә, авыл яшьләренә ярдәм итү, шулай ук аларны ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү системалы эшкә әйләнергә тиеш.

– Бүген дәүләтебезне тотрыклы үстерү, кыйммәтләребезнең дәвамчанлыгын булдыру өчен яшьләр белән эшләү кирәк, – диде Россия Президентының Идел буе федераль округындагы Вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров, утырышны ачып. – Дәүләт яшьләр сәясәте мәсьәләләрен җайга салу аерым игътибар сорый, чөнки тышкы, шулай ук эчке сәясәттә яңа сынаулар чыгып тора, ә аларны җиңәргә кирәк.

Татарстанда яшьләр сәясәтен тормышка ашыру, аларны ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү мәсьәләләре аерым игътибар үзәгендә тотыла. Бүген республикада 380нән артык үсмерләр клублары һәм яшьләр берләшмәләре, студентлар отрядлары, кадет мәктәпләре актив эшли, волонтерлар хәрәкәте уңышлы җәелдерелә. «Юнармия» бөтенроссия балалар-яшьләр хәрби-ватанпәрвәрлек хәрәкәтенең республика отрядлары – илдә иң яхшылардан, ә Татарстан үзе – әлеге хәрәкәтне үстерү буенча Россия төбәкләре арасында лидер.

Фәрит Мөхәммәтшин дискуссиядә миграция сәясәте мәсьәләләренә дә тукталды. Ул вузларда укучы чит ил студентлары һәм хезмәт мигрантлары белән эшне көчәйтергә тәкъдим итте. «Бүген Татарстан вузларында бик күп чит ил студентлары белем ала, республика предприятиеләрендә хезмәт мигрантлары эшли, – дип билгеләп үтте Фәрит Мөхәммәтшин. – Аларны җәмгыятебез тормышына җайлаштыру, мәдәниятләр арасындагы элемтәләрне, милләтара элемтәләрне һәм традицияләрне ныгыту өчен эш формаларын уйлап табарга кирәк.

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Әдәп кануны

Бер мәлне дини табында өстәлгә терсәкләрне куеп утырганмын. Кемдер шелтәләде: «Алай итәргә ярамый, гөнаһ була». Бу миңа бик сәер тоелды. Ислам дине ул – бик күп нәрсәләргә рөхсәт бирә, искәрмә ясый торган киң күңелле дин. Мондый вакытка артык әһәмият бирмидер. Аннан соң, мин – дин тотмасам да, Коръәннең үзем белгән телләргә тәрҗемә ителгән бөтен вариантларын да укып чыккан кеше. Дингә кагылышлы бүтән китапларны да читкә куйганым юк. Алар бит әле тарихи мирас, рухи байлык буларак та бик әһәмиятле. Күп нәрсәләрне тиешенчә аңлый алмаган сурәттә дә алар сиңа әйтеп бетергесез хәзинә бирә: төрле юнәлешләргә этәрә, зиһенеңне һәм хыялыңны чарлый. Гомумән, дингә кагылышлы яхшы китапларны дин әһелләре генә укырга тиеш түгел. Мондый хәзинәдән һәркем файдаланырга тиеш. Ләкин берсендә дә өстәлгә терсәк куеп утыру турындагы сүзне очратканым юк иде. Миңа кисәтү ясаган кеше дә моның ник шулай икәнен әйтә алмады.

Ләкин минем бу хакта беренче ишетүем генә булмаган икән. Кечкенә вакытта берничә кабат шулай әйткәннәрен искә төшердем. Малай чагыбызда өлкәннәр әйткәнне без күп очракта картайгач кына хәтергә төшерәбез, аңлый башлыйбыз бит. Мин дә искәрмә түгел.

Терсәкне өстәлгә куеп утыру ул минем канга сеңгән, гадәткә кергән инде. Гомер буе кабатлана торган бер күренеш ул: терсәкләр – өстәл өстендә, алар арасында – компьютер… Яки дәфтәр, кәгазь бите… Куллар аста булса, мин үземне ниндидер астыртын эш эшләгән, ярамаган гамәл кылган кебек тоям. Бу табынга да күчә торгандыр инде. Шундый сүз бар икән, аның ниндидер сәбәбе булырга тиеш. Әби-бабайлар, кәрәзле телефонда уйный белмәсәләр дә, акылсыз кешеләр булмаган бит инде. Алар һәр нәрсәне исәпкә алып, алдын-артын карап яшәргә тырышкан. Шуңа без күз алдына да китерә алмаслык авырлыкларны җиңеп яшәгәннәр.

Бер мәлне күп кеше җыелган мәҗлестә утырырга туры килде һәм мин әлеге фикернең сәбәбен ачыклагандай булдым. Без, гадәттә, дини йолаларны буй җитмәслек итеп күз алдына китерәбез бит инде. Ләкин кайберләренең нигезендә бөтенләй гади күренешләр ята бугай. Чөнки дин ул борын-борыннан тәмугка яки оҗмахка урын әзерләү белән генә чикләнмәгән бит инде, фани дөнья мәсьәләләрен хәл итү, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләү нигезе дә булган. Кайбер нәрсәләрдә Алла һәм бәндә мөнәсәбәтеннән бигрәк, көнкүреш ихтыяҗларын хәл итү күренеше ята торгандыр.

Хәзер без мул тормышта, иркендә яшибез. Кунак чакырсак та, үзебез барсак та иркен. Элек алай булмаган. Хәтта без үскән вакытта да авыл кешесенең өе кечкенә була торган иде. Ниндидер бәйрәм вакытында шул өйнең олы ягын бушаталар да өстәл коралар. Безнең ише бала-чаганы артык мебельләр кучерелгән кече бүлмәгә тутырып, тәмлүшкәләр белән алдап тоталар, я бөтенләй урамга куып чыгаралар. Чөнки киләсе кунаклар – санап бетергесез. Хәтта иң зур дигән өй дә кечерәеп кала. Алар, кереп, табын янына утырыша. Барысының да кулы – тез өстендә. Чөнки кулыңны өстәл өстенә куярлык, терсәкләрне җәеп утырырлык түгел. Болай итсәң, ике яктагы күршеңне дә кысарга мәҗбүр буласың. Әдәпсезлек була. Димәк, син – башкалар турында уйлый белми торган мәнсез бәндә.

Терсәкләргә бәйле фикернең нигезендә шушы күренеш ятадыр, дип уйлыйм мин. Үз дәвере өчен бик мөһим булган әдәп кануны. Дингә аның бер катнашы да юктыр сыман. Ә сез ничек уйлыйсыз?

Әйтеп кенә бактым

Нигә генә икән?

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Тагын көзгә кердек. Шыбыр-шыбыр яңгыр ява, яфрак коела. Агачтан өзелгән һәр яфрак гомеремнең бер мизгеле кебек. Көз – минем өчен елның иң уйландыра торган фасылы. Менә хәзер дә яшьлекне искә төшереп, дусларны, туганнарны барлап уйга батып утырам. Бер шәһәрдә торып, нигә күрешмибез, кунакка йөрешмибез икән, дим. Хәзер кунак чакырулар юк бугай ул. Һәркемнең кесәсендә телефон, шалтыратып хәл-әхвәл белешәбез дә шуның белән тынычланабыз. Өстәл янында чәй-мәй эчеп, күзгә-күз карап сөйләшеп, серләшеп утырулар га ни җитә инде!

Мәрхүмә балдызым Лена искә төште әле. Азнакайда яшиләр иде алар. Кунакка дәшсәләр, ара ерак дип тормыйча, машинага утыра идек тә чыгып китә идек. Хәтта аларга мунча керер өчен генә дә баргалаган чаклар булды. Ни дисәң дә, бер якка гына да 350 чакрым ара бит бу. Балалары: «Безнең әни белән әти кунак чакырмасалар йә кунакка бармый торсалар, тәмам авыруга сабышалар», – диләр иде. Иң кызыгы: баҗайларда кунакта булу ашап-эчеп утыруга гына кайтып калмый иде. Балалары кунак күңелен күрер өчен төрле уеннар уйлап табалар, конкурслар оештыралар. Хәтта стена газетасы да чыгарып куялар иде. Кунак булу үзенчә бер тамашада катнашу да иде. Мондый кешеләр хәзер бар микән ул? Юктыр, мөгаен. Ә нигә икән? Юкса тормышыбыз да җитеш. Элек кесәләр бераз такыр булса да, бер ярты кыстыра идек тә дусларның хәлен белергә чыгып китә идек. Киләсен алдан әйтеп тору да юк бит әле. Тик, кеше килсә, хуҗа өстәл әзерләми калмый иде. «Бары – бергә, югы – уртак» дигәннәре шул инде ул.

Әйе, бүген нигәдер йөрешмибез. Туган көннәрне хәттә авылларда да кафеда үткәрәбез. Кунакка йөрешү кимү белән татарның асыл бер сыйфаты – кунакчыллыгы да, аш-суга осталыгы да юкка чыга бармас микән?

Элек авылда: «Фәлән кеше бәлешне бик тәмле пешерә, фәлән кешенең гөбәдиясе ашап туйгысыз...» – дип, аш-суга оста хуҗабикәләрнең исемнәрен атап, бармак бөгә-бөгә сөйлиләр иде. Әлбәттә, хәзер авылда кешесе дә аз, халык та картайды. Кешелеккә генә кия торган күлмәкләрен киеп, халык күрсен, дигән сыман урам уртасыннан атлап, ашка баручылар, мөгаен, тарихта гына калыр.

Ашарга такы-токы гына булган заманда бәрәңге пешереп күршеңне чәйгә чакырулар да сәер бер гадәт кебек күңелдә сакланып калыр, ахрысы. Бәрәңге утыртканда, бәрәңге алганда кем алданрак эш бетерә – шул күршесенә булышырга керә иде. Бик күп эшләрне күмәкләп башкара иде авыл халкы. Хәзер үз кабыгыбызга бикләнә барабыз бугай. «Бергә булыйк», «Бердәмлектә – көч» дигән сүзләр ихлас әйтелми кебек. Нигә икән?

Сабакташым Һади Әхтиевкә шалтыраттым. «Нигәдер кунакка чакырмый башладың?» – дигән булдым. «Җәй буе чакырдык бит инде, килмәдегез», – ди бу. Нәрсә булды безгә? Кунакка үзебез дәшү генә түгел, чакырганда да бармый башладык. Тагын бер сабакташым, Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуровның уйлары белән дә кызыксындым, кешеләрнең нигә кунакка йөрешмәүләрен үзенчә аңлатты ул. «Матди байлык кеше күңелендәге рухи байлыкны кысып чыгарды. Бөтен нәрсә акчага сатыла торган заманның бер хикмәте бу», – диде.

Миңа никтер оят иде. Әнә Һади дус күпме чакырып та, бармадым, Казанда яшәүче дуслар, туганнар белән дә айлар буе күрешмибез. Бер танышым: «Казанга Түбән Камадан баҗайлар килгән, безгә кермәсәләр генә ярар иде», – дигән иде. Кая инде ул бер күрергә тилмереп яшәү! Нигә шундый йомыкыйларга әйләндек? Бу сорауга үзем анык кына җавап бирә алмыйм. Укучыларыбыз ни дияр тагын?!

«ИСКЕЛЕК КАЛДЫГЫ»ННАН НИЧЕК КОТЫЛЫРГА?

ЯКИ ОФШОР СУМНАР БАЗАРЫ

Рәшит
ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Сум бата башлагач, Путин сүзчесе Песков тынычландыргыч белдерү ясады: Кремльдә сум курсы өчен борчылмыйлар, макроикътисадый тотрыклылык тулысынча тәэмин ителә, диде. «Чрезмерное внимание к курсу доллара является «рудиментом прошлого», – дип тә өстәде. «Несет пургу» дип Путин кем турында әйткән иде әле? Мин Путин бәясенә ныграк ышанам. Песков сүзләренә Куркынычсызлык советында да ышанып бетмиләр, күрәсең, чөнки икътисадый һәм социаль куркынычсызлык проблемалары буенча советның секция утырышы узды. Утырышта Россиянең Икътисадый куркынычсызлык стратегиясенә үзгәрешләр кертергә кирәклеге турында сөйләшенде. Федераль министрлар һәм дәүләт банклары җитәкчеләре ачыктан-ачык сум курсының Үзәк банкка буйсынмавын әйтә. Доллар үстеме, бәяләр үсә, бу – аксиома. Тотрыклылык берничек тә тәэмин ителә алмый, чөнки базарның үз законнары бар, ул законнар чиновник белдерүләренә һәм югары әмерләргә буйсынмый. Мең стратегия яз, асыл сәбәпләрен юк итмәсәң, девальвация барыбер барачак.

Әле яңа гына Мәскәүдән 400 пассажир Антальягә оча алмый интекте. Алар утырган беренче самолет, моторындагы проблемалар сәбәпле, һавага күтәрелә алмады (бәхеткә дип әйтик инде). Икенчесе шулай ук төзек булып чыкмады. Өченче самолет кына 7 сәгатьтән соң һавага күтәрелде. Очкычлар чит илнеке һәм чит ил компанияләре аларга хәзер хезмәт күрсәтми. Күпме генә стратегияләр язма, тотрыклылык турында күпме генә белдерүләр ясама, күккә күтәрелү проблемасы кискенләшүдән туктамый. Доллар курсы да нәкъ шулай: тышкы сәүдә өчен валюта котылгысыз кирәк. Доллар ел эчендә 50–70 процент табыш бирә башлаган икән, ул акча саклау инструментына да әверелә. Бу юлларның авторы якын киләчәктә «глобаль көньяк» илләренең берсенә барып кайтырга ниятләгән иде, аның өчен шулай ук «рудимент» кирәк. Чит базарларда «рудимент» дип (биологиядә кирәксез әгъзаны шулай атыйлар, без «искелек калдыгы» дип тәрҗемә итәбез) долларларны түгел, сумнарны атыйлар, чөнки безнең Үзәк банк баскан кәгазьләр анда файдасыз.

Валюта базарында хәзер хәлләрнең торышы кызык бит. Төрле илләрдә әллә никадәр чикләүләр бар. Һинд рупияләрен, мәсәлән, тышкы базарларга чыгара алмыйсың. Россия нефте рупияләргә сатылды һәм акчасы Һиндстан банкларында эленеп калды. Дәһли Мәскәүгә кызыклы алмаш тәкъдим итте: рупияләрне Һинд икътисадына инвестицияләргә. Индусларның акылы алтын: бу нефтьне аларга бушка бирүгә тиң, чөнки инвестицияләгән акча табышны рупияләрдә бирәчәк, аларны тагын кайтарып булмаячак. Нефтьчеләр вазгыятьтән чыгу юлын эзли һәм таба да. Баксаң, рупияләрне сумнарга әйләндерү механизмы бар икән. ВТБ банкы башлыгы Костин әйтә ул хакта. Моның өчен Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендәге арадашчылардан файдаланалар. Рупияләр БГӘ банкларына күчерелә (моның өчен криптовалюталарны эшкә җигәләр, диләр). Дубай, рәхәтләнеп, аларны, теләсәң – долларга, теләсәң, сумнарга алыштырып бирә. Сүзне Костин әфәндегә бирик әле: «За такие операции берется комиссия, а суммарные объемы транзакций по вышеуказанной схеме могут достигать сотен миллиардов рублей ежегодно», – ди ул. Шәпме? Шәп! Шәплек гарәпләр өчен, билгеле, чөнки алар компьютер каршында тик утырып кына да миллиардлар эшлиләр. Белдерүдәге «комиссия» дигән сүзгә игътибар итүегезне сорыйм. Комиссия күләме әйтелми. Автор үз каналлары аша белеште: 50 процентка җитә, ди. Димәк, нефть бәясенең илле процентын гарәп банкирларына бирергә туры килә. Әмма эш моның белән генә бетми әле. «Сум курсы» дигән нәрсә бар.


shutterstock.com

Соңгы көннәрдә чит илләрдәге сумнар һәм аларның курсына бәйле рәвештә үзәк хөкүмәттә һәм зур банк җитәкчеләре арасында тавыш чыкты. Финанс министрлыгының Финанс сәясәте департаменты директоры Чебесков сумның рәсми булмаган офшоры формалашуында зур хәвеф күрүен әйтте. Исемлекне дәвам итеп тормыйк, байтак эре түрә дискуссия үткәрде бу темага. Офшор сум базарында кесә калынайтучы банкирлар аны яклады, «Кытай моделе» дип зурладылар. Чебесковка тагын сүз бирик: «Мы видим, что реальность такова, что существует неофициальный рынок рубля в офшорах. Рубли выводятся за границу, там их обменивают на валюту, часть рублей возвращается обратно на внутренний рынок России, часть – нет», – диде ул Мәскәү финанс форумында. Акчаның бер өлеше генә кайта, димәк. Илне кычкыртып талыйлар дип аңларга кирәк моны. Ләкин каза моның белән генә бетми әле. Костин әйтүенчә, Кытай моделенә күчсәк, сумның ике курсы булачак, берсе бездә – 150 сум, икенчесе – 250. Офшор сумнар базарында бүген үк инде сум курсы бик түбән. Валюта өчен анда бик күп сумнар чыгарып салырга туры килә. Ил тагын бер тапкыр талана, банкирлар ота.

Долларны «рудимент» итеп, сумны конвертацияләнә торган валюта итеп буламы? Теоретик яктан була. Моның өчен чит илләр бездән ябырылып ала торган инновацион продуктлар кирәк һәм күп кирәк. Әмма Россиядә инновацион бизнес үсеп китә алмый. Туа ул, ләкин аны яралгы хәлендә үк буалар. Кайсы гына булса да бер предприятие яңа технологик продукт җитештереп сата башламасын, зур бер түрәнең баласы аңа кызыга башлый. Креатив эшмәкәрне төрмә шулпасы эчәргә озаталар. Аннан башка теге предприятие су сипмәгән чәчәк кебек шиңә дә төшә. Бу тактиканы үзгәртергә кирәк бит инде. Шуннан башка технологик суверенитет та була алмый, технологик товарларның экспорты да. Димәк, доллар алдына барып тезләнергә, «параллель импорт» аша кыйммәт бәягә товарлар кайтартырга туры килә.

Сум курсы – стратегик мәсьәлә. Девальвация хәл итеп булмый торган күп проблемалар тудыра. Әйтик, эшче куллар проблемасы. Хезмәт хакының доллардагы күләме кечерәю илдән мигрантларны куа. Алар урынына безнең диван патриотлары эшкә чыкмаячак. Инфляция турында әйтеп тә тормыйк: девальвация белән ул кулга-кул тотынып йөри. Хәтта бензин бәясе дә «рудимент» курсына бәйләнгән. Базар хәле тыюлар белән җиңеләйми. Болттагы сырлар өзелү эффекты башлана, бизнес саботаж ясый, ясалма дефицит тудыра.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ХУШЫГЫЗ, МАЛКАЙЛАР!

ЯҢА ЧИШМӘ РАЙОНЫНДА БЕР-БЕР АРТЛЫ ФЕРМАЛАР ЯБЫЛА

Редакциягә Яңа Чишмә районының Акъяр авылы халкыннан борчулы мөрәҗәгать килеп иреште. «Авылыбызда ферманы ябалар, кырыклап кеше эшсез кала. Инде сыерларны алып китеп бетерделәр, чиратта – яшь таналар һәм бозаулар. Зинһар, килеп, райондагы хәлләрне үзегез дә күреп китегез әле», – дип шалтыраттылар безгә. Озакка сузмыйча юлга кузгалдык.

Зөлфия Хәлиуллина

Тубылгы Тау авылында тәзек фермаларны җимерә башлаганнар.

Буранында сукмагын табасың

Акъяр авылында «ферма ябыла, сыерларны алып китәләр икән» дигән сүзләр ел башыннан бирле йөргән. Тик халыкка барысын да тәфсилләп аңлатучы булмагач, алар ахырга кадәр яхшыга өметләнгән. Өметләр 20 сентябрьдә эштән китү буенча гариза язарга дип кулларына документ тапшыргач өзелгән. Шулай итеп, узган атнада сыерларны алып китеп бетергән, сыер савучыларга эш бөтенләй беткән. Әлегә фермада бүген-иртәгә бозаулаячак сыерлар һәм бозаулар гына калган. Алары да озакка калмас, диләр.

– Бик кызганыч, сеңлем. Гомер буе шушында эшләп, бер кирәксезгә чыгарып калдыргач, ничек күңел төшмәсен инде? Лаеклы ялга да чыгып калып булмады ичмасам, – диде 33 ел шушында эшләгән Татарстанның атказанган терлекчесе Гөлчәчәк Шәйхетдинова.

Аның сүзләренчә, якынча 40лап кеше эшсез калган.

– Эшкә кая урнашасын уйлаганым юк әле. Түбән Камада эш тәкъдим итәләр дә ул, ләкин анда ике көн куна калып йөри торган кеше түгел мин. Авыл белән шәһәр арасы ерак, хуҗалыгым да зур, терлекләрем дә бар. Аларны кемгә калдырасың? Башка хатыннар да шундый фикердә. Үз авылында эшләүгә ни җитә?! Монда ичмасам буранында – сукмагын, яңгырында ышыгын табасың. Чит авылда ятим бала булып йөрисеме? Белмим, алга таба ни эшләп бетәсе булыр, – дип уфтанды Гөлчәчәк Шәйхетдинова.

Халык үзе чакырып китерсә дә, башкалар, кызганыч, без баргач, очрашырга да, фикерләрен әйтергә дә курыктылар. Югалтыр әйберләре дә юк төсле югыйсә: фикерләрен сорамаганнар, малларын төяп алып киткәннәр, эшсез калдырганнар, бүген-иртәгә фермаларының ишегенә йозак эленергә тора. Хәер, «Сез мондагы хәлләрне аңлап бетермисез шул, халык алдакы акчаларын да «кисәрләр», тәрлечә аяк чалырлар дип курка», – дигән сүзләр дә ишеттек. Ферма янына узмакчы булгач, сакта торучы абзый юлыбызга аркылы ук төште. «Безне дә аңлагыз инде, эшсез каласыбыз килми бит», – дип башын гына иде ул. Шулай да механизаторлар белән бераз аралашу җае чыкты. Алар әйтүенчә, фермадан 2 мең тирәсе сыерны алып киткәннәр.

– Сыер савучыларга Түбән Камада эш тәкъдим итәләр, тик үзләре дә аннан безгә килеп йөри бит. Фермада Каргалы, Роман авыллары эшчеләре дә эшли иде. Хәзер беркемнең кирәге калмады. Гади эшченең кадере бетте. Элек безгә хөрмәт зур иде, – диде алар.

Күп тә узмады, машинасында тузаннар туздырып килеп җитеп, үзен сак хезмәте дип таныштырган абзый, бик эшлекле кыяфәт ясап, безне территориядән куып ук чыгарды. Эшчеләр белән иркенләп сөйләшергә, фермага узарга ирек бирмәгәч, «Агро-Основа» агрофирмасы директоры Эдуард Антонов белән сөйләшер өчен, Акъярдан берничә чакрым ераклыктагы Шахмай авылына юл тоттык. Барганда ук артыбызга «койрык» тагылганына игътибар иткән идек инде, авылга кереп, конторага тукталгач та, сак хезмәте хезмәткәре: «Мин монда сезне барыбер беркем белән дә сөйләштермим», – дип, авыз ачарга да ирек бирмәде. Шулай да без үз каналларыбыз аша Эдуард әфәнденең телефон номерын табып, шунда ук үзенә шалтыраттык. Ул башта: «Телефоннан аңлатма бирмим», – диде. Без дә күзгә-күз карап аралашырга теләвебезне һәм контораның ишек төбендә торуыбызны әйттек. Шулай дигәч, ул Түбән Камага китүен һәм төшке аштан соң гына кайтачагын әйтте. Без көтәргә дә риза идек. Тик берничә тапкыр шалтыратуыбызга карамастан, ул очрашырга да, җавап бирергә дә теләмәде.

Тубылгы Тау

Кызганыч, эшсез калучыларның бер Акъярда гына булмавы ачыкланды. Ел ахырына кадәр Тубылгы Тау һәм Сосновка авылларында да фермалар ябылачак икән. Без Акъярдан берничә чакрым ераклыкта гына булган Тубылгы Тау авылы халкы белән дә күрешеп чыктык.

Авылда 700ләп кеше яши. Эшкә сәләтле яшьтәгеләрнең күпчелеге фермада эшләгән. Фермадагы малларны быел җәен ташып, биналарын җимерә башлаганнар. Зур, тәзек, ныклы фермалардан калган кирпеч өемнәрен үзебез дә күрдек. Райондагы фермерлардан килеп ирешкән мәгълүматлар буенча, агрофирма фермаларны арендага да бирергә теләми, техникаларын да башка район фермерларына гына сата икән.

– Авылда бөтен әйберне бетереп баралар. Элеккеге колхоз рәисе төзеткән фермаларга кадәр җимереп киттеләр. Бернинди дә чара күрүче юк. Кешеләр эшсез калды. Хәзер гаиләләрен калдырып, Түбән Камага эшкә йөриләр. Әлегә эш тапмыйча, өйдә генә торучылар да бар, – диде авыл халкы.

Ферма һәм авыл язмышы эшсез калган яшьләргә генә түгел, өлкәннәргә дә тынгылык бирми.

– Мин 38 ел бер җиргә китмичә, шушында эшләдем, – диде Гарәфетдин Кадыйров. – 1200 баш сыерны 80 кеше карый иде. Гөрләп эшләде алар заманында, бар җирдә тәртип иде. Шул фермаларны хәрабәгә әйләндерделәр бит. Халыкка эш юк хәзер. Бу – вәхшилек, дип әйтүдән башка сүз юк.

Без дә шат түгел

Безне районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсендә дә колач җәеп каршы алмадылар. «Яшермим, мин сезне күрүемә шат түгел», – диде җитәкчесе Леонид Богомолов үзебез белән таныштыргач. Шулай да бүлмәсеннән куып чыгармады. Анысы өчен рәхмәт.

Ачык чыганаклардан алынган мәгълүматлар буенча, «Агро-Основа» җәмгыяте Яңа Чишмә районында 2017 елда теркәлгән.

2021 елда хуҗалыкның җиде бүлекчәсендә 8 мең баш терлек исәпләнгән, шуларның 3 меңе сыерлар булган. Әлеге вакытта оешмада нибары 1 мең баш терлек (яшь таналар һәм бозаулар) калган. Соңгы ике елда районда Шахмай, Чертуш һәм Чаллы Башы авылларында фермалар ябылган. Бүген-иртәгә Тубылгы Тау, Акъяр һәм Сосновка авыллары ферма ишекләренә дә кадак кагылачак.

Шунысын әйтеп узыйк: районда терлекчелек белән шөгыльләнүче башка агрофирма юк.

– Моңа мин дә, район башлыгы Вячеслав Козлов та шат түгел. Ләкин бу – килешенгән эш. Ел ахырына кадәр яшь таналар һәм бозаулардан кала, өч авылда фермалар ябылачак. Моның бары тик күчеш чоры булуына гына ышанасы килә. Беркем дә кешеләрне урамга куып чыгармый. Аларга эш урыннары да тәкъдим ителде, социаль түләүләр дә, компенсацияләр дә биреләчәк, – диде Леонид Богомолов.

Идарә башлыгы сүзләренчә, агрофирма сыерларны аз сөт бирүләре, авыру булулары өчен бетерергә карар кылган. Ләкин төп сәбәп – сөт хакларының түбән тәгәрәве, ягъни табыш булмау.

Җитәкчеләр акча санаганда, безне, әлбәттә, авылларның ачы язмышы борчуга сала. Чөнки фермасы, димәк, эше булмаган салаларның киләчәген барыбыз да чамалый.

– Булган эшкә дә кеше таба алмыйбыз бит, – диде моңа җавап итеп Леонид Богомолов. – Фермаларга эшчеләрне читтән китерттек.

Кызганыч, андый проблеманы да инкарь итеп булмый. Киләчәктә агрофирма Тубылгы Тау авылында 1600 баш сыерга исәпләнгән югары технологияле, заманча комплекс төзергә планлаштыруын әйттеләр. Төгәл вакытын сорагач, 2024 елның башы, диде идарә башлыгы. Аның өчен инде мәйдан әзерләнгән, чистартыла башланган, әзерлек эшләре бара. Тик, авыл халкы сүзләренчә, башта шундый вәгъдәләр яңгыраса да, соңгы берничә атнада бу юнәлештә эшләр туктатылганга охшап тора.

Күпчелек малларның авыру булуын Баш ветеринария идарәсе башлыгы Алмаз Хисаметдинов кире какты.

– Бу мәгълүмат дөреслеккә туры килми. Әлеге фермалардагы сыерларның 12 проценты лейкоз белән авырый. Ләкин төп сәбәп ул түгел. Агрофирма аз продуктлы терлекләрне сәламәт малларга алыштырып, киләчәктә заманча комплекс төзергә планлаштыра, – диде ул.

Әлеге хәлләргә аңлатма бирүен сорап, Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына да чыктык. Алар тәкъдим иткән рәсми җаваптан аңлашылганча, «Агро-Основа» терлекчелек фермаларын ике төп сәбәп өчен япкан: аның беренчесе – малларның күпчелек өлеше лейкоз белән авырган, икенчесе – совет заманында төзелгән фермалар югары продуктлы терлекләр асрарга мөмкинлек бирми.

«Киләчәктә ферма 1600 башка исәпләнгән ферма төзеячәк. Ә эшчеләргә үсемлекчелек тармагына күчәргә тәкъдим ителгән», – диелгән иде министрлык җавабында.

Соңгы сүз урынына. Тубылгы Тау авылына баргач, сыерларны төяп алып киткән чакларына туры килдек. Берничә терлекне арбасына төягән тракторны авыл башына кадәр озата бардык. Малкайлар да, мескенкәйләрем, башларын бора-бора, мөгри-мөгри, авыл белән саубуллашкандай итте. Без дә авыз эченнән: «Хушыгыз һәм кичерегез, малкайлар!» – дип пышылдадык.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ЧИР ЧИТЛЕГЕНДӘ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Рекламада күрсәтелә торган дарулардан сак булыйк!»

Гадәттәгечә, алдан бераз статистика. Бу елның 7 аенда Татарстанда грипп белән авыру күрсәткече, 2022 елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, 10,9 тапкыр арткан (2838 очрак). Бу чорда республикада 100 мең кешегә 122,2 грипп очрагы туры килгән.

Россия буенча саннарга килсәк, соңгы атнада грипп һәм ОРВИ белән чирләү күрсәткече 25 процентка кимеде, ди Роспотребнадзор. Коронавирус белән чирләүчеләрнең саны ил күләмендә 16 меңнән артыграк.

Ни өчен көзгә кергәч, чирләр дә кире кайта? Прививкаларның файдасы бармы? Йөткерү, төчкерү кебек чир билгеләре булганда шундук даруга ябышасымы?

Педиатр, медицина фәннәре кандидаты Илдус ЛОТФУЛЛИН белән сөйләшүебез дә шул сорауларга ачыклык кертүдән башланды.

:: Илдус Җәүдәтович, бик наив сорау булса да, сорыйк инде: ни өчен көз җиткәч күпләп авырый башлыйбыз? Әллә җәен иммунитетны тиешенчә ныгытмыйбызмы?

– «Салкын тию» дигән төшенчә чынлыкта салкынга бәйле түгел. Кыш һәм көзен кешеләр күбрәк вакытын тынчу, саф һава булмаган урыннарда, бина эчендә үткәрәләр, шуңа күрә дә күбрәк концентрациядә вирус йоктыралар.

«Салкын тию»не китереп чыгаручы төп вирус – риновирус – салкынча тирәлектә үзен яхшырак хис итә, шул тирәлектә озаккарак тоткарлана. Шул сәбәпле дә кешеләр ешрак чирли. «Салкын тию» салкынга түгел, инфекциягә бәйле.

:: Хәзер коронавирусның яңа штаммнары хакында да күп сөйлиләр. «Пирола» дигәне куркыта. Коронавирус безгә яңа «көчтәнәч»ләр әзерли әллә?

– Фәнни яктан чыгып бу геновариантны «ВА.2.86» дип атау дөрес, «омикрон»нан килеп чыккан ул. Беренче булып ул бу елның июлендә Даниядә табылды. Хәзерге көндә әлеге штамм-вариантның үткәннәреннән начаррак, зәһәррәк формада узуына нинди дә дәлилләр юк. Аның молекуляр структурасы башка, аерылып тора, иммун системасы аны тулысынча танымый. Менә шуңа күрә тарала да инде ул.

Вирусның зәһәрлеген күрсәтүче төп күрсәткечләрнең берсе – төп госпитализация проценты, ягъни инфекция йоктырган кешеләрнең күпме проценты хастаханәгә эләгә – менә шуңа карыйсы. Беренче, икенче, өченче «дулкын»нарны бик яхшы хәтерлибез бит.

Уйдырма	Чынбарлык
Сарымсак ашасаң, чирләмисең	Сарымсак ашау, билгеле, файдалы. Әмма аны күпләп ашау ашказанына зыян салачак.
Антибиотик = дәва	Грипп ул – вирус. Шуңа күрә аннан дәвалангенда вируска каршы препаратлар кулланалар. Нәрсә эчәсен табиб кына билгели ала.
Гриппны дәваларга кирәкми, вакыты җиткәч, уза	Вакытында дәваламасаң, ахыры хәерле булмаска мөмкин.
Прививка ясатам да авырмыйм	Авыру сайлап йөрми, ул кемгә дә ияргә ала. Әмма прививкасы булган кешеләр аны җиңелрәк кичерә.

Госпитализацияләнүчеләр саны күп иде. Мин хәтта үзем дә пневмония белән хастаханәдә яткан идем.

:: Илдус Җәүдәтович, салкын тию, ОРВИ, грипптан дәвалануның төп кагыйдәләрен искә төшерсәк иде. Алайса, без хәзер төчкерсәк тә, йөткерсәк тә, тизрәк даруга, антибиотикка ябышырга күнегеп барабыз бугай.

– Профилактика кагыйдәләре үзгәрмәде, алар шул ук. Бина эчендә һава җилләтелгән һәм саф, ә куллар чиста булырга тиеш. Төчкергәндә һәм йөткергәндә битне капларга кирәк. Үз сәламәтлегебезне алдан ук кайгырту зарур: дөрес туклану (Д витамины һәм тимер җитмәгән очраклар булырга мөмкин), диабет, симерү, кан басымын контрольдә тоту. Аларга игътибар итмәсәк, инфекцияне эләктереп чирләү авыр формада узарга мөмкин.

Дәвалауга килгәндә, ОРВИ белән чирләгән кешегә дару түгел, ә аның хәлен дөрес итеп бәяләү кирәк. Әгәр дә чир катлаулы булмаган формада уза икән, дару эчүдән тыелып торырга була. Антибиотик урынына күпләп су эчү, антиконгестант (сосудосуживающее) урынына томау төшкән борынны тозлы су белән яхшылап юдыру күпкә нәтиҗәлерәк тә, зыянсызрак та. Чир катлаулы формага күчкәндә генә табиб антибиотик билгели.

Нәтиҗәлелеге исбатланмаган дарулар турында да онытмыйк. Фәнни телдә «плацебо» дип әйтсәк, халык аларны «фуфломицин» дип йөртә.

Рекламада шундый яхшы иттереп «иммунитетны күтәрүче», «вирус-бактерияне үтерүче», «салкынны тиз арада кайтаручы» дип тәкъдим ителүче дарулар хакында сүзем. Тискәре яклары өйрәнелмәгән «противовирусный», «имунномодулятор» дарулар аптекада сатылса да, алар зыянлы булырга мөмкин. Мең дә бер төрле БАДларга да кагыла бу. Сак булыйк! Ни кызганыч, шул исбатланмаган даруларны һәм БАДларны җитештерүчеләрнең акча эшләү теләге шул бу.

Кайсы ковид та кайсы грипп?

Кайсы вирус нинди чир китереп чыгарганын түбәндәге билгеләр буенча чамаларга мөмкин.

Уртак билгеләр	Кайсына нәрсә хас?
•Хәлсезлек •Буыннар һәм мускуллар сызлавы •Баш авыртуы •Интоксикация (агулану) •Кызышу синдромы (лихорадка) 	•Грипп очрагында температура кисәк күтәрелә һәм югары күрсәткечкә менә (38–39 градус). •Аденовирус инфекцияләре һәм парагрипп очрагында температура – 37,5, сирәк очракта 38дән югарырак була. •Гриппның беренче көннәренә «коры борын» хас, ягъни борынга томау төшми. •Риновирус инфекциясе вакытында борын тыгыла. •Аденовирус инфекциясе вакытында тамакта авырту сизелә, конъюнктивит барлыкка килергә мөмкин, лимфа төеннәре зурая. •РС-инфекция очрагында пневмония билгеләре күзәтелергә мөмкин (ютәл, сулыш алу кыенлашу). Балалар өчен ул аеруча куркыныч тудыра.

Искәрмә: төгәл диагноз кую өчен, лаборатория тикшерүе узарга кирәк!

:: Вакциналар да күп хәзер. Прививка кадатканда, кайсын сайлыйсы, үзенә яраклысын ничек табасы?

– Узган сезонда грипп авыр үтте, кешеләр бу начар инфекция белән икешәр тапкыр чирләде. Балаларда да чир шактый кискен барды. Гриппка каршы вакцина кадату – инфекциягә каршы көрәшнең төп юлы.

Вакциналар төрле була. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасының тәкъдиме мондый: ясала торган вакцинада 4 төрле компонент булырга тиеш, һәрберсенең микъдары 15 микрограммнан аз булмасын. Импорт вакциналарның барысы да моңа туры килә. Россиядә ясала торганнарның «Ультрикс Квадри» дигәне шулай ук әлеге таләпләргә җавап бирә. 6 айдан башлап рөхсәт ителә ул. 65 яшьтән өлкәнрәкләргә, үпкә авырулары булган кешеләргә пневмококктан да вакцина ясату дөрес булыр.

:: Прививкага каршы булган кешеләргә ни диярсез? Нинди киңәш бирерсез?

– Ниндидер усаллану, ачу белән җавап бирәсем килми. Болай да күп ич инде усаллык бу дөньяда, инде табибтан да усаллык чыгарга тиеш түгел. Явызлык булышмый да ул. Кешеләргә чакыру, эндәшү, мөрәҗәгать белән: «Бу сорауга эмоция-хис ягыннан түгел, фикер йөртү ягыннан чыгып, рациональ карагыз әле!» – дияр идем.

:: Ата-аналарны соңгы вакытта коклюш дигән чир дә борчый. Аннан ничек сакланырга һәм дәваланырга?

– Юкка гына түгел шул бу куркулар. Мин инде табиб булып 15 ел эшлим, коклюшның шулкадәр көчле булган чагын хәтерләмим. Пандемиянең бер кайтавазы бу дип фаразлаучылыр бар. Вакцинасыз балаларның күп булуына да бәйлиләр моны.

Эпидемиология күзәтүләре ничектер, ә минә үзенең эш урынында һәр педиатр коклюшның ешаюын күрә. Коклюштан 100 процент нәтиҗәле дәва юк. Беренче атналарда антибиотик эчү (макролид төркеменнән булганын) буылып ютәлләүне җиңеләйтерә. Башка дарулар, кызганычка, нәтиҗә бирми.

Вакцинация коткара инде, әлбәттә, башка чара юк. Бәләкәй балаларга да ясала ул. 6 яшьтә ревакцинация ясау дөрес. Зурларга да ревакцинация ясау бик хәерле.

Кайгырмыйча кайгыртасы

Вируслы инфекцияләрнең көзге чорда «чәчәк атуы» ел саен күзәтелә. Республика Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш инфекционисты Халит Хәйретдинов билгеләп үткәнчә, 2020–2022 еллар гына искәрмә була ала. Ник дигәндә, бу елларда коронавирус хакимлек итте. «2020 елда грипп булмады диярлек. 2021 елда «дельта-штамм»-ның тәэсире кими башлагач, грипп килеп чыкты. Аннан «омикрон» пәйда булды да гриппны чигерде. Бер инфекция чыгып тора, өстенлек итә, калганнары бу вакытта үзен күрсәтми», – ди белгеч.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов сүзләренчә, сезонлы чирләрнең күтәрелешенә аптырыйсы юк. «Барысы да җәйге каникуллардан һәм ял көннәреннән соң коллективка кайта бит: балалар – мәктәпләргә һәм балалар бакчаларына, өлкәннәр эшкә бара», – ди ул.

Иммунитетны ничек ныгытырга соң? Терапевт, пульмонолог Олег Абакумов бу җәһәттән менә ни ди:

– Сәламәтлекне температура югары күрсәткечкә җитеп, борынга томау төшкәнче үк кайгыртa башларга кирәк. Урамда градус үзгәрү дә чирләр һөҗүменә сәбәпче. Иреннәр ярыла, борын асты кызара башлау да вируслар һөҗүме турында сөйли. Организмны беренче салкыннарга ияләштерергә кирәк. Иммунитетны ныгытуның беренче адымы – сәламәт йокы. Тулысынча караңгыда йокларга кирәк. Бер үк вакытта йокларга яту мөһим. Төнге 12дән дә калмаска тырышыгыз. Йоклар алдыннан телефонда утырмаска кирәк. Кәһвә, энергетикларны тормышыгыздан сызып ташлыйсы. Йоклар алдыннан 400 мг магний эчәргә кирәк. Өегездә һава дымландыргыч булса, бигрәк тә яхшы. Бу сулыш өчен генә түгел, тән тиресе матурлыгы өчен дә файдалы.

Олег Абакумов сүзләренчә, күпләп су эчү дә мөһим. Тәүлегенә 1,5–2 литр эчәргә киңәш ителә. Су туйдырса, морс, үлән чәйләренә күчәргә дә ярый.

– Баллы тәм-томнарны читкәрәк алып куясы, күп итеп яшелчә, җиләк-җимеш ашарга кирәк. Иммунитет өчен аксым да мөһим. Шуңа күрә рационга тавык һәм күркә итен кертү хәерле. Энергия өчен ярмалар җаваплы, – ди табиб.

Көзге-кышкы чорда А, С витаминнары, кальций белән дуслашырга кирәк. «Әфлисун һәм башка цитруслы җиләк-җимеш, алма, карлыган, киви, баллы борыч, чөгендер, укроп, тозлы кәбестәгә игътибар итегез», – дип киңәш итә белгеч.

Олег Абакумов физик күнегүләр хакында да онытмаска куша. Тернәкләнү һәм физик активлык өчен иң яхшысы – йөгерү һәм фитнес, ди ул. «Штангага тотынырга, стадионда кисәк йөгерә башларга киңәш итмим. Паркта салмак кына йөрергә, велосипедка утырырга мөмкин», – дип искәртә белгеч.

Белеп тор!

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе вируслы авырулар сезонына кагылышлы сорауларга җавап бирү өчен «кайнар элемтә» үткәрәчәк. Кызыксындырган сорауларны 2–13 октябрь аралыгында иртәнге сәгать 9дан кичке 5кә кадәр бирергә мөмкин.

Телефон номерлары: 238-52-11, 238-96-84.

ХАЛЫК АВАЗЫ

13 октябрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Зөһрә САДЫЙКОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

Гөнаһмы бу?

Мин 30–40 ел элек рус милләтеннән булган күрше әбине ул кушканча җирләдем. Фатиры миңа калды. Шуннан соң бер генә мәртәбә дә зиратка барганым булмады. Күптән түгел, Сухая река ягында урнашкан зиратка күршемнең каберен эзләп бардым. Таш куймаган идем. Шуңа күрә таба алмадым. Зираттагы дәфтәрдәге исемлектә дә юк. Инде үземә 85 яшь тула, теге дөньяга барасы бар бит. Каберен карамаган өчен миңа җавап бирергә туры килерме? Гөнаһмы бу?

Тәнзилә ЯРУЛЛИНА. Казан

Рөстәм Ясәвиев, Казандагы «Рәхмәтулла» мәчете имам-хатыйбы:

– Әгәр бу сорауны бирүче апа мәрхүмәне җирләүне оештырган, әйтик, каберен казыткан, җирләткән икән, иншалла, бурычы үтәлгән дип беләбез. Килешүдә зиратта һәйкәл, таш кую яки башка вазыйфалар булмаган икән, зыян булмас.

Казанның кайбер зиратларында урын бетү сәбәпле, ничәдер ел узгач, иске каберләр өстенә күмү гадәте бар. Бәлкем, ул яңа кабергә әйләнгәндер. Бу очрак өчен артык борчылырга кирәкми, дип уйлыйм.

Тупылга карап, ызанны бүлеп буламы?

Ике арада утыртылган тупыл бар иде. Ул ызан булып торды. Койма тотмадык. Агач 30 ел элек киселде, төбе генә бар хәзер. Миңа туксан яшь тула. Мин үлгәч, балалар күрше белән ачуланышып йөрмәсен өчен, ызан мәсьәләсен хәл итәргә кирәк иде. Күршеләрем вафат, анда балалары яши.
1966 елда йорт салганда, янгын сүндерүче килеп, кагыйдәне аңлатты. Бер генә метр да читкә чыгасы түгел, югыйсә йортыгызны сүттерәм, диде. Без шул тәртиптә салдык. Документлар бар. «Җир» оешмасыннан белгеч чакырттым. Арага казык кагып кит, дигәч, какмады. Читкә тайпылган, ди. Күршеләргә бу мәсьәлә буенча кергән юк. Гомер буе ызан булып торган шушы тупыл уртасыннан бүлеп биреп буламы икән? Элеккеге кагыйдә бүген үз көчендәдер бит?

Р. ГЫЙМАДИЕВ.
(Районым редакция өчен)

Булат Закиров, юрист:

– Аңлашылганча, җир участоклары хуҗалары үз участокларының чикләрен үзгәрткән, әмма моны берничек тә теркәмәгән.

Әлеге үзгәрешләр тиешенчә рәсмиләштерелсен өчен, җир участогы чикләрен үзгәртү өчен, законлы нигез кирәк.

Мондый нигезләр булырга мөмкин:
– бүләк итү
– сату-алу.

Күршедән участокның бер өлешен сатып алуның ике төп ысулы бар.

1. Аның җирләрен ике яки аннан да күбрәк участокка бүлеп, чиккә тоташкан җирне сатып алырга.

Участок бүлгәндә, күршенеке ике, өч яки аннан да күбрәк өлешкә бүленә. Кадастр инженеры чик планын рәсмиләштерә һәм теркәлгәннән соң Росреестрда ике участок һәм ике милек хокукы барлыкка килә. Шуннан соң аларның берсен стандарт схема буенча сатарга яки бүләк итәргә мөмкин.

2. Күрше җирне сезнең җир мәйданыгызны арттыру яки участок конфигурациясен үзгәртү өчен бүлеп бирергә мөмкин.

Күршедән участокның бер өлешен сатып алу башка схема буенча бара: күрше җирдән ниндидер мәйдан кисеп алына һәм сезнең территориягә кушыла. Димәк, милек хокукы объектлары саны саклана, ләкин җирнең мәйданы һәм конфигурациясе үзгәрә.

Күрше белән килешү булмаса, үз хокукларыгызны судта яклап була. Бу очракта үзегезне хаклы дип санарга нигез кирәк.

Шулай ук Росреестрга мөрәҗәгать итәргә киңәш бирәбез.

Җавапларны Сәрия МИФТАХОВА әзерләде



Чулпан Гарифуллина

9 октябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

5.05, 6.05, 7.05, 8.05 «Вести-Татарстан. Погода»
5.35, 6.35, 7.35, 8.35 «Вести-Татарстан. Утро»
9.00 «Яңалыклар. Татарстан»
9.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

6.00, 7.10, 2.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
7.00, 18.30, 20.30, 5.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
10.00 «Көтелмәгән кунак 2». Телесериал 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 16.00 «Халкым минем...» 12+
12.00, 22.10 «Укытучылар». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней+». Карбоновые полигоны: зачем они нужны и смогут ли «починить» планету? Интервью с Марией Кожевниковой 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә»: «Акыл батл» һәм «Учимся вместе» 0+
16.30 «Көтелмәгән кунак 2». Телесериал 16+
17.30 «Татарстан без коррупции» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
23.00 «Садовница». Телесериал 12+
00.00 «Соотечественники» 16+
00.25 «Каравай». Вышитая карта 6+
00.50 «Путь» 16+
01.05 «Нәсыйхәт» 16+
01.30 «Татар халык җырлары» 0+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлар белән) 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Празат Исәнбәт турында телеочерк 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.35 «Әнием нең җыры кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Калеб» 6+
21.55 «Туган авылым» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Ватандашлар» 16+
02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Заһидулла һәм Фарит Яруллиннар турында телеочерк 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал 16+
15.15 Премьера. «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
19.55 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Сергей Безруков в сериале «Бизон: дело манекенщицы» (S) 16+
23.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Однажды к прочтению» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
02.35, 3.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.00 Новости
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 Премьера. «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ЛИХОРАДКА» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьевым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.40 Детективный телесериал «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25, 05.30 «Игра миллионов» 12+
06.30 «Все о главном» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 19.50 Новости
07.05, 15.30, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Легендарные клубы» 12+
11.25 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 6+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 «География спорта. Новосибирск» 12+
16.25 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Тюмень» – «Торпедо» (Москва). Прямая трансляция
18.30 «Громко» Прямой эфир
19.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Локомотив-Кубань» (Краснодар) – МБА (Москва). Прямая трансляция
22.00 Дартс. Профессиональная лига. Про Тур 7. Прямая трансляция
00.55 Волейбол. БЕТСИТИ Кубок столетия. Финал 4-х. Мужчины. Финал 6+
02.55 Новости 0+
03.00 Автоспорт. СМП РСКГ Эндуранс. Кубок России 6+
05.00 «Наши иностранцы» 12+

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 «ПЁС» 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» 16+
22.10, 00.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» 16+
00.50 «МЕДИАТОР» 18+
03.10 «ГЛАЗА В ГЛАЗА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.40, 05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.35 «Давай разведемся!» 16+
08.35, 02.25 «Тест на отцовство» 16+
10.45, 23.05 «Понять. Простить» 16+
11.55 «Порча». «Пригворенный». «Обсидиан» 16+
13.00, 01.10 «Знахарка» 16+
13.35, 01.35 «Верну любимого» 16+
14.10, 02.00 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45, 04.05 «Кризисный центр» 16+
19.00 «ПЕРЕЗВОНЮ ПОЗЖЕ» 16+
00.15 «Порча» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «ВНИМАНИЕ, ГОВОРИТ МОСКВА!» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 00.55 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА» 12+
12.45, 13.25, 15.05, 17.15, 03.35, 5.35, «СЛЕПОЙ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Оружие холодной войны». «Штурмовой удар» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Ищу своих» 12+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «БЕЗ ПРАВА НА ПРОВАЛ» 12+
02.10 «Неизвестная война. Великая Отечественная» 16+
02.55 «Легендарные полководцы. Петр Багратион» 16+

10 октябрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

5.05, 6.05, 7.05, 8.05 «Вести-Татарстан. Погода»
5.35, 6.35, 7.35, 8.35 «Вести-Татарстан. Утро»
9.00 «Яңалыклар. Татарстан»
9.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 7.10, 2.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 5.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
10.00 «Көтелмәгән кунак 2». Телесериал 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплете». К 90-летию серии популярных биографий «ЖЗЛ» 16+
11.30, 22.10 «Укытучылар». Телесериал (татар телендә) 16+
12.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Адмирал» – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
15.00, 19.00, 21.30 Новости Татарстана 16+
15.15 «Семь дней+». Как и для чего популяризировать науку? Интервью с Искандером Гилязовым 16+
15.45 «Шаян ТВ» тәкъдим итә: «Учимся вместе» 0+
16.00 «Татарлар» 12+
16.30 «Көтелмәгән кунак 2». Телесериал 16+
17.30 «Заман көзгесе» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
23.00 «Садовница». Телесериал (Россия, 2019) 12+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Если хочешь быть здоровым». Кардио, гипертония 16+
00.40 «Путь». Царица неба и земли 16+
00.55 «Не от мира сего...» Никольская церковь 16+
01.05 «Туган җир» 12+
01.30 «Татар халык җырлары» 0+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлар белән) 16+
04.45 «Болгар радиосы» бәйрәм концерты 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «Бизон: дело манекенщицы» (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
01.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
02.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+
02.45, 03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Эйзенштейн 125» 16+
03.00 Новости
03.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ЛИХОРАДКА» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьевым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.40 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25, 05.30 «Игра миллионов» 12+
06.30 «География спорта. Новосибирск» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55 Новости
07.05, 15.30, 19.15, 21.45, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Легендарные клубы» 12+
11.25 Смешанные единоборства. UFC 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 «Что за спорт?» 12+
16.25 «Магия большого спорта» 12+
16.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Салават Юлаев» (Уфа) – «Автомобилист» (Екатеринбург)
19.25 Хоккей. OLIMPBET Чемпионат МХЛ. «Крылья Советов» (Москва) – «СКА-Юниор» (Красногорск). Прямая трансляция
22.00 Дартс. Профессиональная лига. Про Тур 7. Прямая трансляция
00.55 Регби. PARI Чемпионат России. «Динамо» (Москва) – «Локомотив-Пенза» 12+
02.55 Новости 0+
03.00 Стрельба из лука. Кубок мира. Итоги сезона 0+
04.05 «Динамо» Ленинград». Документальный фильм 12+
05.00 «Голевая неделя. РФ» 6+

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 «ПЁС» 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» 16+
22.10, 00.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» 16+
00.50 «МЕДИАТОР» 18+
03.00 «ГЛАЗА В ГЛАЗА» 16+
04.35 «Военно-исторические маршруты» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.20 «Давай разведёмся!» 16+
08.20, 02.30 «Тест на отцовство» 16+
10.30, 23.15 «Понять. Простить» 16+
11.40 «Порча». «Овощи». «Приглашение на похороны» 16+
12.45, 01.15 «Знахарка» 16+
13.15, 01.40 «Верну любимого» 16+
13.50, 02.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.25 «Твой Домашний доктор» 16+
14.40, 04.10 «Кризисный центр» 16+
19.00 «БЕЗ ТЕБЯ МНЕ ЖИЗНИ НЕТ» 16+
00.20 «Порча» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «СЛЕПОЙ» 16+
07.00 «Сегодня утром». 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 01.05 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА» 12+
15.35, 17.15 «СЛЕПОЙ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Оружие холодной войны» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого». «Дело о климатическом оружии: США против России» 16+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «НЕПОДСУДЕН» 12+
02.15 «Неизвестная война. Великая Отечественная» 16+
03.05 «Хроника Победы» 16+

ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНУ, ДӘВАЛАНУ ҺӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ ҺӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ ҺӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР ҺӘМ ГАРАНТИЯЛӘР



ШАУЛАМА, КОЛАГЫМ!

Җир йөзендә яшәүче һәр өч кешенең берсе колак шаулаудан интегә. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы белгечләре шулай дип чаң суга. Шаулавы бер бәла булса, аның җитди чир башлангычы булуы икеләтә куркыныч, ди белгечләр. Колак шаулаудан ничек котылырга? Аны булдырмый калырга мөмкинме?

Лор-табиб Алсу САБИРОВА колак шаулау турында сөйләде.

➤Колак шаулаганда, кешегә гүләгән, чыелдаган, сызгырган тавышлар да ишетелергә мөмкин. Ул тавыш су агышын, йөрәк тибешен дә хәтерләтә ала. Тынлыкта ул көчәя генә бара.

➤Колак шаулаудан котылу өчен, иң элек аның ни сәбәпле пәйда булуын ачыкларга кирәк. Эшне колак шаулауга китергән чирне дәвалаудан башлыйбыз. Әйтик, әгәр колак умыртка баганасының муен өлешендәге проблема аркасында шаулый икән, физик күнегүләр ясау, массаж, бассейн да ярдәм итәчәк. Колак шаулаудан интеккән кеше күңел төшенкелегенә дә бирелергә мөмкин. Андый чакта күпләр антидепрессантлар эчә башлый. Шуңа күрә колак шаулауга җиңел карарга ярамый, вакытында дәваларга кирәк.

➤Колак шаулаудан интегү колакчыннар ярдәмендә акыртып музыка тыңлаган кешеләр арасында да еш очрый. Моннан тыш шул рәвешле чукраклану куркынычы да зур. Башка киеп куела торган зур колакчыннар күпкә куркынычрак санала. Ник дигәндә, аларда тыгыз вакуум пәйда булмый, чит тавышлар да керә. Шуңа күрә кеше, яхшырак ишетү өчен, музыка тавышын тагын да катырак ача. Бу исә – колак өчен зур зыян.

➤Эчке колак күзәнәкләре, ишетү нервы үлә башласа, кеше акрынлап чукраклана. Моңа кан әйләнеше бозылу, атмосфера басымы кисәк үзгәрү аркасында алынган җәрәхәтләр, йогышлы авырулар да сәбәпче булырга мөмкин. Әгәр кеше нәрсә әйтүеңне кат-кат сорый, артык каты кычкырып сөйләшә башлый, телевизор караганда тавышын чамадан тыш көчәйтә икән – шикләнергә җирлек бар. Болар – чукраклануның беренче билгеләре.

Үзем сынадым

КОЛАК ШАУЛАУДАН КОТЫЛДЫК

Берара кызым колак шаулаудан интекте. Танышым бер ысул өйрәткән иде, шуның файдасы күрдек. Сез дә саклап куегыз. Аның өчен төнгә каршы 1 стакан укроп орлыгына 2 стакан кайнар су коеп, өстен капкач белән капларга һәм төнәтергә кирәк. Төнәтмә кәстрүлдә ясалса яхшырак. Шуны көнгә өч тапкыр икешәр аш кашыгы эчәргә. Төнәтмә беткәнче дәваланасың. Өч ай дәвамында шулай ясап эчкәч, колак шаулауның эзе дә калмый.

Гөлфия САЛИХОВА. Балтач

vk.com

Нигә шаулый?

✓**Югары кан басымы.** Колаклар шаулавы еш күзәтелә. Хәтта моны гадәти хәл дияргә дә була. Шул ук вакытта кешенең башы сулкылдап авыртырга, күз аллары караңгыланырга да мөмкин.

✓**Шешләр.** Әгәр колак шаулау әкренләп арта барса, баш миендә яисә ишетү органнарында шеш булырга мөмкин. Андый чакта кешенең күңеле болгана, колагына төрле тавышлар ишетелә, күзләренең күрү сәләте кими, хәрәкәт иткәндә тигезлек тә югала.

✓**Азканлылык.** Колак шаулауга китергән иң еш сәбәпләрнең берсе – тимер җитешмәү аркасында пәйда булган азканлылык. Шул сәбәпле кеше тиз арый, каты тирли, йөзе агара, һава җитмәү, күз аллары караңгылану кебек билгеләр дә күзәтелә.

✓**Колак юлы томалану.** Колакка су керсә яки колак сагызы тупланса, кеше диңгез ярына бәрелгән дулкыннар тавышын ишетеп тора. Колак юлын чистарткач, колак шаулавы да басыла.

✓**Эчке колактагы тайпылышлар.** Колак ялкынсынганда һәм эчке колакка сөяк үскәндә, колакларда куыклар шартлаган, шарт-шорт килгән, шыгырдаган тавышлар ишетелә.

Табигать даруханәсе

Таҗы гына түгел

Ярату-яратмауны ачыкларга ярдәм иткән ромашка күп кенә чирләрдән дә шифа булып тора. Белгечләр, әлеге чәчәк һәр йортта ел дәвамында сакланырга тиеш, дип искәртә.

Тамак авыртканда. Икешәр чәй кашыгы кипкән ромашка чәчәге белән юкә чәчәген алабыз да өстенә 500 мл кайнар су салабыз. Ярты сәгатьтән артык төнәтергә кирәкми. Соңыннан сөзеп алып, шуның белән көненә өч-дүрт тапкыр тамакны чайкатабыз.

Артрит, артроз, ревматизмнан. 3 литр суга 200 г ромашка салып, ут өстенә кайнатырга куябыз. Кайнап чыгуга ук, табакка бушатабыз һәм аякларны шунда тыгып утырабыз.

Ашказаны һәм уникеилле эчәк җәрәхәте вакытында. 1 аш кашыгы киптерелгән ромашка чәчәген 1 стакан кайнар суга салып, 1 сәгать төнәтергә

pinterest.com

кирәк. Ашарга ярты сәгать кала яки ашаганнан соң 1,5–2 сәгатьтән җылы килеш эчәргә һәм 10 минут саен янга, аркага, корсакка әйләнеп ятасы булачак.

Күзән җыерганнан. 1 аш кашыгы үләнгә 2 стакан кайнар су алына. Шул төнәтмәне көн дәвамында аз-азлап, ашау араларында эчәргә кирәк.

Киңәш

МУЕНГА ҖИЛ БӘРСӘ

Күзгә чорда муенга җил бәрү еш күзәтелә. Авыртудан котылу өчен, түбәндәге компрессларның файдасы тими калмас. Керән тамырын угычның эре тешләре аша чыгарып, шуңа 2–3 аш кашыгы үсемлек мае кушарга кирәк. Марляга салынган шушы катнашманы авырткан урынга целлофан пакет яки шарф ярдәмендә бәйләп куеп, 20 минут ятып торасы.

ИМБИР ЮТӘЛДӘН КОТКАРА

Ютәл үзәккә үтсә, имбирле чәй коткарачак. 4 аш кашыгы вак уылган имбиргә 2 л суда 10 минут пешерәбез дә, бераз суынгач, 6 аш кашыгы бал яки 4 аш кашыгы әфлисун согы кушып, җылы килеш эчәбез. Теләге булган кеше сөт тә куша ала. Сүз уңаеннан, имбир микробларны үтерә, кан әйләнешен яхшырта, иммунитетны ныгыта, ялкынсынуны һәм авыртуны баса, какырыкны куптара, температураны һәм кан басымын төшерә, тынычландыра. Шулай да ашказаны һәм уникеилле эчәк җәрәхәте, гепатит, аритмия, аллергия булганда, имбир белән дәваланырга ярамый. Ул диабетка каршы һәм йөрәк даруларының тәэсирен дә көчәйтә. Ике яшькә кадәрге балаларга имбирле дарулар бирергә ярамый.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

КАБАКЛЫ РЕЦЕПТЛАР

shutterstock.com

Быел кабак бик уңды. Әлеге файдалы яшелчәне күбесенчә мал ризыгы гына дип кабул итеп, бераз кадерен җибәрәбез кебек. Иренмәсәң, аннан әллә нинди тәмле һәм файдалы ризыклар әзерләп була бит. Тәмле һәм ансат рецептлар тупланмасын сезгә тәкъдим итәбез.

КАЙНАТМА > Диләрә Галиева рецепты

Кирәк: кабак – 1 кг, лимон – 1 данә, әфлисун – 1 данә, шикәр комы – 800 г.
Әзерләү: кабакны зуррак, төшләре алынган әфлисун белән лимонны ваграк шакмак итеп турарга. Аларның өстенә шикәр комы салып болгатып, 10–12 сәгать торгызыгыз. Аның суы чыгачак. Аннары кайнатып чыгарып, бик әкрен утта сиробы куерганчы 1 сәгать чамасы кайнатыгыз. Куерып китү сәбәпле, көймәсен өчен болгаткалап торыгыз.

СОК > Мәрьям Миннегулова рецепты

Кирәк: кабак – 5 кг, су – 11 литр, әфлисун – 6 данә, лимон кислотасы – 2 аш кашыгы, шикәр комы – 1 кг 100 г.
Әзерләү: Төрле рецептлар бар интернетта, мин менә шулай эшләдем, әйбәт чыга. Кабакны әрчеп, бик эре булмаган кисәкләргә бүлеп, кәстрүлгә салырга. Шуның өстенә 11 литр салкын су салып, кайнап чыкканда, 6 әфлисунны иттарткычтан чыгарып өстәргә. Кабаклар пешкәч, изелә башлагач, 1 кг 100 г шикәр комы салып кайнатырга. Сүндереп, вак тишекле дуршлаг аркылы сөзеп, 2 аш кашыгы тулыр-тулмас лимон кислотасы салып кайнатып чыгарырга, күбеген җыярга. Стерильләштергән банкаларга тутырырга.

ГАРНИР > Гөлзамия Нурмиева рецепты

Кирәк: кабак – 500 г, сарымсак – 1 тырнак, томат пастасы – 1 чәй кашыгы, кипкән рәйхан – чәй кашыгы, зәйтүн мае – 1 аш кашыгы, тәменчә тоз белән борыч.
Әзерләү: чистартылган кабакны зур шакмак итеп турарга. Зәйтүн маенда 7 минут чамасы кыздырырга. Тәменчә тоз белән борыч, рәйхан, томат пастасы өстәргә һәм изелгән сарымсак салып болгатырга. Аннары фольга белән каплап, 180 градуслы мичтә ярты сәгать пешерергә. Әлеге гарнирны ит белән табынга бирергә була.

АШ > Резеда Ганиева рецепты

Кирәк: кабак – 600 г, суган – 1 данә, помидор – 3 данә, бәрәңге – 4 данә, сарымсак – 2 тырнак, татлы борыч – 1 данә, сыр – 100 г, үсемлек мае, тәменчә тоз, бизәү өчен чистартылган кабак төшләре, 1,5 л су яки ит шулпасы, сохари ясау өчен батон яки ипи.
Әзерләү: кабак, болгар борычы, суганны турыйбыз, сарымсакны угычта уабыз. Үсемлек маенда болгар борычын суган белән 7 минут чамасы кыздырабыз. Аңа кабак өстәп кыздыруны дәвам итәбез. 5 минуттан аңа туралган помидор, сарымсак һәм тәмләткечләрне салып кыздырабыз. Шулпага бәрәңгене салып пешерәбез. Барысын бергә шулпага салып, кайнатып чыгарабыз. Ахырда уылган сыр өстәп, тиз генә болгатабыз. Сыры эрегәннән соң, сүндереп, бераз суытабыз. Аннары яхшылап блендерда изәбез.

Сохари өчен шакмаклап туралган батон яки ипине майлы табада кыздырып алабыз. Ашны тәлинкәләргә бүлгәндә, өстенә сохари салып, кабак төше сибеп бирәбез.

САЛАТ > Лилия Гыйниятуллина рецепты

Кирәк: кабак – 350 г, консервланган ногыт борчагы – 250 г, фета сыры – 160 г, суган – 60 г, көнбагыш мае – 75 г, лимон согы – 1 аш кашыгы, сарымсак – 2 тырнак, соя соусы – 3 аш кашыгы, тәменчә кара борыч, бераз кунжут орлыгы, петрушка.
Әзерләү: чистартылган суганны ярымбоҗралап, кабакны шакмаклап турыйбыз. Тирән табага үсемлек мае салып, кабакка борыч сибеп кыздырабыз. Йомшарганнан соң кабакны уттан алып суытабыз. Фета сырын 1 сантиметрлы шакмаклар рәвешендә турыйбыз.
Соус болай әзерләнә: изелгән сарымсакны лимон, соя соусы, көнбагыш мае катнашмасына салып болгатабыз. Аннары соусны да кушып, барысын бергә болгатабыз һәм табынга өстенә көнҗет белән петрушка салып бирәбез.

КОЙМАК > Алсу Зарипова рецепты

Кирәк: кабак – 500 г, он – 160 г, шикәр комы – 2 аш кашыгы, тәменчә тоз, көпшәкләндергеч (1 чәй кашыгы) яки серкә белән сүндерелгән ярты чәй кашыгы сода, йомырка – 1 данә, көнбагыш мае – 60 мл.
Әзерләү: шакмаклап туралган кабакны, бераз су салып, 20 минут кайнатырга. Пешкән кабакны блендерда изәргә. Кабакка он белән көпшәкләндергеч салып болгатырга. Аннары йомырка, тоз, шикәр комы өстәп тугларга. Коймак кебек пешерергә һәм табынга бал белән бирергә.

ПИРОГ > Алисә Камалиева рецепты

Кирәк: кабак – 440 г, атланмай – 120 г, йомырка – 3 данә, лимон – 1 данә, шикәр комы – 140 г, он – 150 г, сода – 1 чәй кашыгы.
Әзерләү: чистартылган кабакны угычның эре тишекле, ә кабыгы белән лимонны вак тишекле ягында уарга. Лимонның суын сыгарга. Атланмайга башта шикәр, аннары йомырка салып болгатырга. Аңа лимон, аннары кабак белән он өстәп туглауны дәвам итәргә. Аннары лимон суы белән сүндерелгән сода салырга. Майланган табада 180 градуска кадәр җылытылган мичтә ярты сәгать пешерергә.

Яз өчен көздән

Бакчачыга

Җылы, коры көннәрдә теплицаны киләсе сезон өчен әзерләп куйсаң яхшы.

1 Теплицадагы корыган үләннәр, чергән яшелчәләрне һәм туфракның 7 см чамасы өстәге катламын җыеп алып ташларга киңәш ителә. Бу чүп үлән орлыклары, яшелчәләрдәге чир һәм туфрактагы бөҗәкләрдән котылу өчен шулай эшләнә.

2 Туфракка тирес, торф, көл кертеп казып куярга кирәк. Берәр сидерат та сибеп, туфракны баетып җибәрсәгез дә әйбәт булачак.

3 Туфрак өстенә хәзер салам җәеп куеп, кыш көне кар кертсәгез, теплица туфрагы киләсе сезон өчен тагын да яхшырак булып өлгерәчәк.

4 Теплицаны тузаннан арындырып, сөртеп, каркасының металл өлеше күгәрә башласа, буяп куярга иренмәгез. Тишелгән урынын ямарга, асылынган ишеген тарттырып куярга да онытмагыз. Вак кына җитешсезлекләрне вакытында карамау кыйммәткәрәк чыгарга мөмкин.

Укучы киңәше

Гортензия әче ярата

Утырту өчен 50х50 см зурлыгында чокыр казыйбыз. Аның төбенә бер чиләк черемә, булса, әче торф яисә ылыслы урман туфрагы салырга. Туфракка 50 г күкерт коллоиды һәм 200 г суперфосфат кушып, бергә бутыйбыз да гортензиянең тамыр муентыгы белән тигез итеп утыртабыз.

Берәр таякка бәйләп куябыз һәм җитәрлек итеп су сибәбез. Быел бездә корылык булганлыктан, казыган чокырыбызны башта суга туендырабыз, аннары гына утыртабыз. Әче торф булса, аны һичшиксез кушыгыз. Себеркесыман гортензия әче туфракны ярата. Ә күкертне суалчаннар туфрак белән бергә эшкәртеп, аны әчетәләр. Аны елга ике-өч тапкыр коры килеш чәчәкнең төбенә сибеп чыгарга кирәк.

Мүлчәләгән вакытта ылыс яки салам кулланыгыз. Алар кышны чыгарга ярдәм итә. Кышка кергәнче, төбенә су сибәргә онытмагыз.

Фәридә ЗӘЙНУЛЛИНА

БЕР УРЫНЫНА БИШНЕ БИРМӘ

Яшерен-батырын түгел, кредитлы-бурычлы заманда яшибез. Әмма ислам динендә процентлап, ягъни арттырып түләү шарты белән бурычка акча, фатир, машина һәм башка милек сатып алу хәрам гамәл санала. Шул рәвешле, дини күзлектән караганда, ипотека, кредит, «рассрочка» дигән төшенчәләргә карата да шик туа. Фатирда вакытлыча яшәп тору ипотека алуга караганда дин буенча кулайракмы? Риба нәрсә ул? Бурыч тозагыннан котылу өчен нишләргә?

Башкаланың «Мәрҗани» мәчетеннән Ансар хәзрәт МИФТЯХОВ белән шул хакта сөйләштек.

:: Хәзрәт, нәрсә ул риба?

– Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим. Риба ул – процент. Ягъни процентка акча биреп тору яисә алу. Әҗәткә акча биргән вакытта кеше шул акчаны кире кайтарган вакытта күпмедер күләмдә артыграк акча таләп итә икән, бу бәндә рибага кергән була. Процент сораган кеше дә, арттырып түләгән кеше дә гөнаһлы санала. Әйтик, 2 мең сум акчаны бер атнадан соң 2500 иттереп кайтар, дисә, 500 сумы риба саналачак.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) бер хәдисендә: «Бер дирһәм риба алу яисә бирү Кәгъбәтуллаһ янында газиз анасы белән 17 тапкыр зина кылу белән бер», – дип кисәтә. Ягъни риба – зинадан да зуррак гөнаһ. Инди генә җирлектә яшәсәк тә, бу хәрам гамәлдән ерак булу кирәк.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә риба хакында менә ни ди: *«Риба ашаучылар ахирәттә шайтан зәхмәте суккан кеше кебек торыр. Аларның бу хәле «Сату-алу да нәкъ риба кебек бит», – дигәннәре өчен. Хәлбуки Аллаһы Тәгалә сату-алуны, сәүдәне хәләл кылды, ә рибаны хәрам кылды. Әгәр берәү Раббысы тарафыннан үгет-нәсыйхәт килеп ирешкәч тыелса (риба ашаудан туктаса), элек кылган рибасы гафу ителәр һәм аның эше Аллаһы хөкеменә тапшырылыр. Кем кабаттан риба алса, ул җәһәннәм әһеле булып, анда мәңге калыр. Аллаһы Тәгалә рибадан бәрәкәтне ала, сәдаканы исә үстерә»* (Бәкара, 275–281).

:: Ислам динендә ипотека тыела, дибез. Үз куышын булдырырга теләүчеләргә нишләргә соң? Гомер буе арендалап тору да мөмкин түгел бит. Димәк, ипотекага алган фатирда яшәгән кеше гөнаһлы булып чыгамы инде?

– Ислам динендә ипотека тыела. Үз куышын булдырырга теләүчеләргә шуны әйтәсе килә: хәзерге көндә шәригатьчә эшләп килүче банклар бар. Алар махсус хезмәтләр тәкъдим итә, хәләл ипотека бирәләр.

Әгәр ипотекага алган фатирда яшәүче шәригатебездә моның тыелган гамәл икәнен белмичә алган икән, иншә Аллаһ, Аллаһы Тәгалә үзе кичерер. Бу – белмичә кылынган гамәл, белмичә эшләнгән эш. Әмма белә торып алсак, гөнаһлы булу да мөмкин. Хәләл ипотекага күчсәләр, хәерле.

:: Безнең илдә кредитсыз яшәү мөмкин хәл түгел. Анысы да – хәрам. Кешегә нишләргә соң?

– Кредит алу мәсьәләсенә килгәндә, аларны да дини яктан чишү ысуллары бар хәзер. Бу эшләрне хәләл банкларга тапшырырга мөмкин. Кредит сорап, банкка мөрәҗәгать иткәнче, бәлки, хәлләрәк туганнардан, дуслардан акча алып тору кулайрак булыр. Банкка акча түләп торганчы, туганыңа, дустыңа бирү күпкә хәерлерәк. Процентсыз, үз вакытында кайтару шарты белән, билгеле.

Аллаһы Тәгаләнең динен хаталы дип танырга кирәкми. Болай яшәп булмый, болай мөмкин түгел, димик. Аллаһы Тәгалә рибаны тыйган икән, бу юкка түгел. Һәрбер эшебез гамәл дәфтәренә язылып бара, барысы өчен дә җавап бирәсе.

:: Ә «рассрочка»дан (кичектереп түләү) файдаланырга рөхсәт ителәме?

– Кичектереп торуны шәригатебез рөхсәт итә. Әйтик, кеше кибеттән 5 мең сумлык товар ала да кибет белән килешү төзи. Шушы биш меңне, мәсәлән, биш айга бүлеп, берәр мең итеп шул аралыкта кайтарам дип килешсәләр, бу рөхсәт ителгән гамәл булыр.

:: Бурыч йөгеннән котылу өчен дога юкмы?

– Түбәндәге догаларны укырга мөмкин.

1 Аллаһүммә инни әгүзү бикә минәл-һәмми үәл-хәзәни үәл-гаҗзи үәл-кәсәли үәл-бухли үәл-җубни үә даләгыйд-дәйни үә галәбәтир-риҗәл.

Мәгънәсе: Әй, Аллаһым! Мин тынычсызлыктан һәм кайгыдан, гаҗизлектән һәм ялкаулыктан, саранлыктан һәм куркаклыктан, бурычның авырлыгыннан һәм кешеләрнең золым кылуларыннан Сиңа сыенам.

2 Әллаһүммә раббәс-сәмәәүәәти вә раббәл-әрдый вә раббәл-гаршил-газыыйми раббәнәә вә раббә күлли шәйин. Фәәликул-хәбби вәннәвә вә мунзиләәт-тәүрааты вәл-инҗиили вәл-фуркаан. Әгүүзү бикә мин шәрри күлли шәй ин әнтә әәхыйзун бинәәсыйәтиһ. Әллаһүммә әнтәл-әүүәлү фәләйсә кабләкә шәй ун. Вә әнтәл-әәхыйру фәләйсә бәгъдәкә шәй ун. Вә әнтәз-заһиру фәләйсә фәүкакә шәй ун, вә әнтәл-бәәтыйну фәләйсә дүүнәкә шәй ун. Икъдый гәннәд-дәйнә үә әгънинәә минәл-фәкъри.

Мәгънәсе: Аллаһым! Әй, күкләрнең, җирнең һәм бөек тәхетнең Иясе! Әй, безнең Раббыбыз һәм бөтен нәрсәнең Раббысы! Әй, орлыкларны тишелдерүче һәм Тәүратны, Инҗилне һәм Коръәнне индерүче бөек Аллаһы! Һәртөрле начарлыклардан Сиңа сыенамын. Элек – Синсең. Синнән элек һичбер нәрсә юк иде. Соң – Синсең. Синнән соң да һичбер нәрсә булмаячак. Син ачыксың. Синнән өстен бернәрсә юк. Синнән бөек һичбер нәрсә юк. Әй, Раббым! Безгә бурычларыбызны түләргә ярдәм ит һәм безне фәкыйрьлектән коткар.

3 Әллаһүммә әкфини би хәләликә ган хәрәмик вә әгънини бифадликә гаммән сивәк.

Мәгънәсе: Әй, Аллаһым, син биргән хәләл ризыклар син биргән хәрам ризыклардан мине ерагайтсыннар иде. Әй, Раббым, кешегә мохтаҗ булмыйча, кешедән ярдәм сорамыйча, синнән генә ярдәм сорасам иде.

Белеп тор!

Хатын-кыз ничек киенергә тиеш?

Коръәни Кәримдә һәм пәйгамбәребез галәйһиссәламнең хәдисләрендә дә хатын-кыз киеменә карата булган таләпләр ачык билгеләнгән. Ул түбәндәге шартларга туры килергә тиеш.

1. Бит һәм беләзеккә кадәр кулларыннан кала тәннең барлык өлешләре дә капланырга тиеш.

2. Кием артык игътибарны җәлеп итәргә тиеш түгел, ягъни купшы булмаска тиеш.

3. Кием үтә күренмәле булмаска тиеш. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Киенгән, ләкин шул ук вакытта ялангач булган, йөргәндә селкенеп йөрүче һәм шулай итеп ирләрне үзләренә каратучы хатын-кызлар җәннәткә кермәячәкләр һәм хәтта хуш исен дә исләмәячәкләр», – дип әйткән.

4. Кием киң булырга тиеш, ягъни тәнгә сыланып торырга тиеш түгел.

5. Киемнән хушбуй исе килергә тиеш түгел.

6. Киемнәре башка динне тотучыларның киемнәренә охшарга тиеш түгел.

7. Кеше әлеге кием белән халык арасында танылуны максат итеп куярга, ягъни киемнең төсе яки ниндидер бизәкләре белән халык арасында аерылып торырга тиеш түгел.

(«Шура» дини альманахыннан)

Хикмәтле сүз

«Әгәр Аллаһының биргән нигъмәтләрен санап карасагыз, һич санап бетерә алмассыз. Шиксез, Аллаһы ярлыкаучы вә рәхимле».

«Нәхел/Умарта кортлары», 16:18

«Үзеңә үлем килгәнчегә кадәр Раббыңа гыйбадәт кыл».

«Хиҗер», 15:9

«Никахта булган хатыннарыгыз белән яхшы мөгамәләдә булыгыз».

«Нисә/Хатыннар», 4:19

«Ий, кешеләр! Без сезне (бер) ирдән вә хатыннан (ир белән хатын буларак) яраттык һәм дә бер-берегезне белеп таныр өчен халыклар вә кабиләләр иттек. Хакыйкать ки, арагыздан Аллаһы каршысында иң хөрмәтлегез – иң тәкъва булучыгыз. Аллаһы Белүче вә һәр эшегездән хәбәрдар».

«Хуҗурат/Бүлмәләр», 49:13

ru.freepik.com

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

И туган тел, и матур тел...

Мин = милләт

Асыл

СВЕТЛАНА РОМАНОВА, ЧУАШ, 26 ЯШЬ

Светлана матурлык ярата һәм кешеләрне тагын да гүзәлрәк итә. Ул – визажист, модель. Макияж серләренә дә өйрәтә.

Көндәлек тормышымда **ЧУАШ ТЕЛЕНДӘ** сөйләшергә тырышам. Бигрәк тә әти-әни, туганнар, якыннар, ирем белән. Тышкы кыяфәтемдә дә чуаш милләтеннән булуымны күрсәтергә җай табам. Чуашиягә кайтсам, милли ризыкларны татып карамыйча калмыйм. Уяв, Акатуй кебек бәйрәмнәрне үз итәм, катнашырга тырышам.

ГАИЛӘБЕЗДӘ БАРЫСЫ ДА ЧУАШ ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШӘ. Кайбер традицияләр әле дә саклана. Мәсәлән, Акатуйга (Сабан туе) җыелабыз. Кышны озату бәйрәмен билгеләп үтәбез, чуаш җырларын башкарабыз.

ТЕЛЕБЕЗНЕ ЮГАЛТСАК, ҮЗЕБЕЗНЕ ЮГАЛТАЧАКБЫЗ. Ата-бабаларыбыз бөртекләп җыйган, саклаган, безнең буынга тапшырган мирасны югалтачакбыз дигән сүз... **ТАМЫРЛАР, ЭЛЕМТӘЛӘР ЮК БУЛАЧАК...** Без башкаларның мәдәни кыйммәтләре астында калып, башкаларны зурлап, башкаларның уй-фикерләрен, тойгыларын үзебезгә алып, үзенчәлегебезне югалтачакбыз.

ЧУАШЛАР – БИК ТЫРЫШ, НЫК ХАЛЫК. Тарихи юлда алар үзләрен югалтмаган, сынауларга бирешмәгән. Ә телебез нинди матур! Җырлап тора! Әйтик, «матур» сүзенең генә дә бездә 50дән артык синонимы бар.

Киләчәктә үз балаларымны тәрбияләүдә әти-әни, әби-бабаларым үрнәген алачакмын. **АЛАР МИҢА МОХИТ ТУДЫРДЫ.** Гаиләдә көндәлектә туган телдә аралашу булса, милли көйләр тыңласалар, китаплар укысалар, ана телен азмы-күпме беләчәк бала. Үсә төшкәч исә аңа нинди гаиләдән булуын, нәселе, милләте турында күбрәк сөйләргә кирәк. Алар башкалардан нәрсә белән аерылып торуын, уникаль булуларын белсен.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде. Фото: Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ

11 октябрь | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

5.05, 6.05, 7.05, 8.05 «Вести-Татарстан. Погода»
5.35, 6.35, 7.35, 8.35 «Вести-Татарстан. Утро»
9.00 «Яңалыклар. Татарстан»
9.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 7.10, 02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 5.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
Бу елъязмага ышансаң, Казан җире халыклары – нигездә элеккеге болгарлар һәм аларның нәсел-нәсәпләре, Идел-Урал буе финнары, ягъни хәзерге мари, мордва һәм удмуртларның ата-бабалары, чуашлар, башкортлар һәм Алтын Урданың төрле төбәкләреннән күчеп утырган кешеләр – барысы да Казанда Мәхмүт ханның хакимлек итә башлавын сөенеп каршы алганнар.

:: Уналтынчы гасыр Казаны нинди булган? «Шәрык башкаласы» дигән исемгә җисеме туры килгәндер, дип уйлыйк.

– Халыкара сәүдә үзәге буларак, Шәрык һәм Көнбатыш Европа илләрендә дә билгеле булган ханлык башкаласы Казан артык зур шәһәр булмаган. Аның тау башында урнашкан һәм көчле ныгытмалар белән уратып алынган өлеше (кирмән) якынча 10 гектар мәйданны биләп торган. Шул заман кешеләре: «Казан ныгытмасы бик нык – таш тау кебек», – дип язып калдырганнар. Казансу һәм Болак ягыннан әлеге стеналарның калынлыгы 5–6 метрга җиткән. Ул урыннар һичкем дә ала алмаслык булып саналган. Кирмән стеналарында башнялар һәм капкалар да булган. Төньяк өлешендә ак таштан салынган һәм төбәнәк кенә стена белән ныгытылган хөкүмәт резиденциясе урнашкан. Хан сарае матурлыгы һәм архитектурасының камиллеге ягыннан аерылып торган. 1565–1568 елларда төзелгән «Теркәү китабы»нда күрсәтелгәнчә, Хан сарае каршында соңгы елларда археологлар тарафыннан тикшерелгән «Зур пулат» исемле ак ташлы бина урнашкан. Хәзерге Сөембикә манарасы янында Хан һәм тагын да ерактарак Нур-Али мәчетләре калкып торган. Хан мәчете янында гына ханнар зираты барлыкка килгән. Археологлар казып тикшергән таш төрбәдә Мәхмүт (1464 елда вафат) һәм Мөхәммәт-Әмин (1518 елда вафат) исемле ханнарның каберләре табылды.

Хан резиденциясе каршында, әмма аннан читтәрәк урнашкан мәйданда шәһәрнең мөселман руханилары башлыгы, күренекле дәүләт эшлеклесе, шагыйрь Кол Шәриф исеме белән аталган сигез манаралы Җәмигъ мәчете һәм ул заманнарда югары мәктәп вазыйфасын үтәгән мәдрәсә эшләп торган. Археологлар аның хәрабәләрен Благовещение соборы каршындагы бакчада таптылар. Мәчет нигезе астына 1552 елның фаҗигале көзендә зур гына ике акча хәзинәсе күмеп куйганнар. Ул хәзинәләрнең берсендә Мәскәү, Псков, Тверь, Рязань, Можайск һәм кайбер башка рус шәһәрләрендә сугылган 1449 көмеш тәңкә, икенчесендә күн янчыкка төрелгән 556 тәңкә яшерелгән.

Кирмәннең соңрак «Туп сарае» («Пушечный двор») дип аталган төньяк-көнбатыш өлешендә хәрби гарнизон, корал остаханәләре һәм сугыш кирәк-яраклары арсеналы урнашкан була. Казан кирмәненең калган территориясен дәүләт идарәсенә якын торган аксөякләрнең, замандашлары язганча, «бик матур һәм гаҗәпләнүгә лаек» бай утарлары биләп торган, сарай хезмәткәрләре яши торган гади генә йортлар, ашлык саклау амбарлары тезелеп киткән. Ханлык чорында шәһәр бистәсе дә кереп-чыгып йөрү өчен 9–10 башнясы булган имән диварлар белән әйләндереп алына. Ныгытмалар 3–4 метр биеклектәге балчык калкулыклар өстенә бер-берсенә терәтеп утыртылган агач буралардан гыйбарәт булган. Буралар эченә туфрак һәм эре-ваклы таш тутырганнар.

:: Сәүдәгәрләр башкалабызга юкка гына агылмагандыр. Димәк, борынгы бабаларыбыз менә дигән һөнәр осталары булган?

– Бистәнең Казансуга якын өлешендә кара һәм төсле металл кою мичләре, тимерчеләрнең, чүлмәкчеләрнең, тире-күн эшкәртүчеләрнең күпсанлы остаханәләре, ә Болак тирәсендә Таһир мунчасы урнашкан була. Хәзерге Үзәк стадионга каршы якта, элеккеге Тазашак урамы тирәсендә, даими эшләп торучы зур гына базар булган.

Башка урыннарны гади агач йортларда яшәүче шәһәр кешеләре, сәүдәгәрләрнең һәм һөнәрчеләрнең утарлары алып торган. Алар арасында мөлкәтле кешеләрнең, бай сәүдәгәрләрнең агач бүрәнәләрдән, сирәк булса да кирпечтән салынган, шул заман кешеләре язганча, икешәр катлы «гаҗәпләндерерлек матур» йортлары аерылып торган. Шунысы кызганыч: бистәләрдәге мәчетләр турында хәбәрләр сакланмаган.

«Казан ханлыгы чорында Кремль» – Фиринат Халиков картинасы.

> Мөселман шәһәрен диварлары төсле чынаяк плитәләр белән капланган мәчетләр һәм аларның югарыга омтылган манараларыннан башка күз алдына да китереп булмый. Шул мәчетләре бит инде шәһәргә үзенә бертөрле матурлык биреп торган һәм чит ил кешеләре аны «искиткеч шәһәр», «Шәрык башкаласы» дип атаганнар.

Шәһәрнең төп өлеше, әлбәттә, сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләр бистәсеннән гыйбарәт булган. Ул көнбатыштан – Болак елгасы, көнчыгыштан – Кара, Ак, Мунча, Шакшы (Поганое) күлләре, көньяктан исә хәзерге Лобачевский һәм Астрономия урамнары белән чикләнгән 60 гектар чамасы мәйданны биләп торган. Кызганыч, археологик казулар вакытында һөнәрче остаханәләре бик сирәк очрый, әмма алар кулланган инструментлар һәм шул остаханәләрдә җитештерелгән әзер продукция – тимерчеләр ясаган хезмәт һәм сугыш кораллары, күптөрле көнкүреш кирәк-яраклары, алтын-көмеш бизәнү әйберләре археологик табылдыклар арасында еш очрый. Чүлмәкчеләр аерууча оста һөнәр ияләре саналган. Алар эшләгән югары сыйфатлы балчык савыт-саба һәм кош-хайван сурәтендәге уенчыклар матур формалары, үзенчәлекле бизәкләре белән аерылып торган. Хатын-кызлар өчен бизәнү әйберләре ясаганда, зәркәнчеләр бакырга, алтын-көмешкә чокып рәсем төшерү, кыйммәтле ташлар кую, металл үрү кебек катлаулы ысуллар кулланганнар. Алтын-көмеш әйберләр хан сараена аеруча күп кирәк булган. Замандашлары язганча, һәр яңа хан үзенә кыйммәтле таҗ, алтын-көмештән савыт-саба эшләткән, кыйммәтле кием-салым тектергән. Мәскәү Кремленең Кораллар палатасында сакланган уникаль «Казан бүреге» кешеләрдә бүген дә зур соклану уята. Аны XVI гасырның беренче яртысындагы татар зәркән сәнгатенең гүзәл үрнәге дип атарга мөмкин.

Һөнәрчеләр арасында төзелеш белән мәшгуль кешеләр аерым бер төркем тәшкил иткән. Алар патша пулатлары һәм биек манаралы мәчетләр салучылар гына түгел, ә төрле төстәге кирпечләр, матур бизәкле гипс плитәләр эшләүче осталар да булганнар. Таш кисүчеләрнең байлар заказы буенча искиткеч матур итеп эшләнгән, матур каллиграфия белән гарәпчә текстлар язылган кабер ташлары безне әле дә хәйран калдыра.

> Казан ханлыгы икътисадында сәүдә, бигрәк тә тышкы сәүдә зур роль уйнаган. Татар сәүдәгәрләре Мәскәү Русе, Кавказ һәм Урта Азия, хәтта Көнбатыш Европа илләре белән тыгыз элемтәдә торганнар. Иделнең Казанга якын Кунаклар утравында ел саен даны еракларга таралган Казан ярминкәсе уздырылган.

Кыскасы, Казанда тормыш дәрәҗәсе шактый югары булган. Бу аңа бай һәм мул тормышлы дигән дан китергән. Ул, чыннан да, атаклы Шәрык шәһәрләренә охшап торган. Әмма, дөрес әйтәсез, мондый тарихны халык белми, туристларга да җиткерелми. Бу юнәлештә эшләрне башларга да, дәвам иттерергә дә кирәк, әлбәттә. Мәсәлән, Таһир мунчасының, кирмәннән кала башка биләмәләр уратып алынган урыннарда башняларның кайда торганлыгы билгеле. Бу хакта хәтта мәгълүматлар язып кую да зур кызыксыну уятыр иде. Казанның бит бүген дә ислам дөньясы башкаласы булудан туктаганы юк. Димәк, бер генә нәрсәне дә игътибарсыз калдырырга ярамый.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

АЛТЫН ЗУР БУЛМЫЙ

Аның кебекләрне кечкенә дә төш кенә дип тә әйтәләр. Тормыш кыенлыкларына бирешмичә, үз юлын тапкан Балык Бистәсе районының Олы Елга авылы кызы Рәмзия Фәттахова – күпләргә үрнәк.

Кечкенә генә гәүдәсенә күпме яхшылык сыйган аның. Балачагында күп кенә сынаулар узса да, сынмаган, аларны җиңеп чыгарга көч тапкан.

– Без – гаиләдә өч бала. Мин – уртанчысы. 7 яшемә кадәр сау-сәламәт булганмын. Мәктәпкә барыр вакыт җиткәндә, сөякләрем сына башлаган. Ялганып кына бетә, тагын сына. Бик нык азапландым инде. Шуңа күрә укуым да өйдә генә булды, – дип сөйли Рәмзия.

Сөяк сынулар озак дәвам итә. Әмма шуңа да карамастан Рәмзия 9 нчы сыйныфны тәмамлагач, Казанга укырга китәргә карар кыла. Интернат-мәктәптә укый башлый. Биредә аның кебекләрне укыталар да, дәвалыйлар да икән. Сынган саен бер аягы икенчесеннән 17 сантиметрга кыскаруын күреп алалар. Рәмзиягә катлаулы операция кичерергә туры килә. Аягын озынайтыр өчен Илизаров аппаратын куялар. Кыз сер бирми. Култык таякларында йөри башлый. Табиблар, берүк егыла гына күрмә, дип кисәтә. Ничек итсә итә, Рәмзия аякка баса. Казандагы 40 нчы һөнәр училищесына укырга керә. Күн мозаикасы төркемен сайлый.

– Мин анда бик яратып укыдым. Бәхетемә, шул елны Казан дәүләт мәдәният-сәнгать университетында кул эшләренә өйрәтә торган юнәлеш ачылды. Мин шул төркемгә эләктем. Укырга керә алдым. Өйдә укысам да, билгеләрем начар түгел иде. Училищены «бишле»гә генә тәмамлагач, югары уку йортында уку кыен булмады. 2005 елда дипломлы белгеч булып чыктым, – ди Рәмзия.

Әле аны университеттан тиз генә җибәрмиләр. Осталыгын, тәҗрибәсен күреп алып, укытырга калуны сорыйлар. Рәмзия биредә 8 ел студентларны өйрәтә.

– 2014 елда районга кайтып киттем. Әнинең бик тә үз янына кайтарасы килде. Казанга килгән иде ул. Без аның белән бер маршрут автобусында каядыр бардык. Шунда әни, өйгә дип, эмаль чүмеч алган булган. Автобуста кеше күп вакыт иде. Шактый озак бардык. Өйгә кайтып сумканы ачсак, теге чүмеч изелеп беткән. Әни шунда бик курыкты. Кызым, монда синең сөякләреңне генә түгел, үзеңне сытып бетерәләр икән, диде. Юл йөрү арыткан иде инде, – ди Рәмзия. – Хәзер авылда яшим. Авыл мәдәният йортында эшлим. Үземнең түгәрәгем бар. Балалар иҗат үзәгендә дә эшли башладым. Телләгән һәр кешене кул эшенә өйрәтәм. Бәйли дә беләм, чигәм дә, күннән, агачтан, керамикадан да эшләнмәләр ясыйм. Казан җөе белән чигүне дә өйрәндем. Бөтен төр кул эшен беләм. Әлегә башкаларны челтәрле үрүгә өйрәтәм. Бу – Казан татарлары уйлап чыгарган уникаль чигү. Монда ике эшне берьюлы башкарасың. Ике җепнең берсен ялгыйсың, икенчесе белән бизисең. Бик матур килеп чыга. Шул рәвешле намазлык чиккән идем, бәйгедә җиңдем.

Рәмзия әтисе белән әнисенә бик рәхмәтле. Алар булмаса, нишләр идем икән, ди ул.

– 45 яшемдә дә иркә бала әле мин. Әти-әни җылысында яшим. Кайчак сәламәтлегем аркасында аларга булыша да алмыйм. Шунысы гына читен инде. Шулай да тик торганым юк. Аксак күп йөрер, диләр бит әле. Минем турында ул. Кайтып та кермим кайчак. Үземә дә, тик тормыйсың, диләр. Йөрим әле йөргәндә, күп утырдым инде өйдә, дим аларга. Күңелемне төшермим. Тормышка сөенеп яшим, – ди Рәмзия.

Булганнан бар да була! Рәмзия машина да йөртә икән инде. Беренче машинасын дәүләт ярдәмендә алган. Икенчесенә үз тырышлыгы белән ия булган. Инде менә быел тагын яңарткан. Чит ил машинасында җилдерәм, ди.

– Әти белән әнинең гараж ишеген ачып озатып калулары да кадерле. Тизрәк алар янына кайтасым килеп тора. Әле озак еллар аларны сөендереп яшәргә язсын. Мин бик бәхетлемен. Хикмәт буй озынлыгында түгел, – ди ул. – Янымда гел яхшы кешеләр булды. Берәү дә күңелемне төшермәде. Үземнең дә тормышка үпкәләп утырырга вакытым юк. Башкаларга да үз юлларын табуын телим.

КАДЕРЕН БЕЛМӘГӘННӘР

Сарман районының Дүсем авылында гомер итүче Марат Юнысов башкалар кебек түгел. Язмышы да гыйбрәтле.

Өстәвенә битендәге шешен күреп тә гаҗәпкә калучылар бар. Әмма ул бу хакта үзе бер дә кыенсынмыйча, һәркем аңларлык итеп сөйли.

– Гемангиома ул. Туганда ук булган. Әнигә шунда ук табиблар, бу баланың баш миенә зыян килергә мөмкин, дип кисәткән булалар. Бу шеш кешегә күчми, – ди Марат. – Әти белән әни мине табибларга күп йөртте. Өч яшемдә шешнең үлчәмен дә киметмәкче булалар. Тик ул барып чыкмаган. Мондый бала 20 яшькә дә җитми дип кайтарып җибәргәннәр. Шөкер, быел 50не тутырдым инде. Дөньяны яратсаң, яшисең икән.

Дөрес, Маратка, битендәге шешне алып атабыз, дип әйтүче табиблар да була. Әнәсе, 3–4 операциядән соң берни калмаячак. Әмма ул ризалашмый. Язмышына ни язылган, шуңа риза булып яши башлый. Гаилә кора, балалары туа. Кызына – 10, малаена 4 яшьтә тормыш ачысы белән очраша ул.

– Көз ае иде. Эштән кайтсам, өйдә ут юк. «Әниегез кайда?» – дим. Балаларым әниләренең аларны бер машина белән кайтарып куйгач, үзенең каядыр чыгып киткәнен әйтте. Шалтыраттым, җавап бирми. Борчуга калдым. Ике көн үтте, хатыным кайтмады. Полициягә хатынымны эзләүләрен үтенеп, гариза яздым. Аны эзли башладылар. Әбераздан чит номердан үзе шалтыратты. Мин башка кешегә кияүгә чыгам, туйлар узгач, балаларны кайтып алам, ди. Аяк астымда җир убылдымыни? Ничек инде башкага кияүгә чыга? Талашып та яшәмәдек бит! Балаларны алып китәм дигәне бөтенләй аяктан екты, – дип сөйли Марат. – Гаиләмне таркатасым килмәде. Кайтсан, гафу итәм, дидем. Бер айдан «мине кыйныйлар» дип хәбәр салды. Кире кайтты. Әйбәт кенә яшәп киттек. Әле күрәселәр алда булган икән. Ярты ел узгач, безгә чит ир-ат килеп керде. Баксаң, хатынымның интернет аша танышкан яңа яры икән. Сөйләштек. Ире һәм балалары барын белмәгән. Хатыным үзен килеп алуын сораган.

Шунда Марат икенче тапкыр авыр хәлдә кала. Берзаман сумкаларын тутырып куйган хатыны килеп чыга. Кызы әнисенең аяк астына ятып ялвара, китмәвен үтенә. Тик ана бала аша атлап чыгып китә. Марат аерылышырга һәм ана хокукларыннан мәхрүм итәргә дип гариза тапшыра. Атна-ун көн дә үтми – хатын тагын кайтып керә. Иремне төрмәгә утырттылар, гафу ит, дип ялына. Марат тагын ышана һәм алдана. Яратуы көчле буладыр инде. Бер ай яшәгәч, хатыны янә чыгып китә. Бу юлы, Сарманга эшкә барам, ди. Шул китүдән 14 ел узган инде. Хатыннан бернинди хәбәр юк.

– Тормышымның асты өскә килгән вакытлар иде бу. Ярый янымда әнием булды. Әгәр ул булмаса, белмим, нишләр идем. Ничек итсәм иттем, балаларны кешегә бирмәдем. Хатын югалгач, туганнары, килеп, сабыйларны интернатка бир, дип киңәш иттеләр. Әнәсе, мин – инвалид, әни пенсиядә. Менә бу сүзләрне ишетү дә җиңел булмады. Нишләп мин балаларымны ятимнәр йортына бирергә тиеш ди әле? Мин исән бит! Бирмәдем. Үзем амбарда эшләдем, әнием балалар карады, – ди Марат.

Әнисенең ташлап китүен кызы авыр кичерә. Сабый авыруга сабыша. Гел тыны кысылып азаплана. Марат баласын табибларга йөртә башлый. Тикшеренә торгач, нервлары какшаганын әйтәләр. Махсус дарулар язып бирәләр. Ахыр чиктә, шул дарулар бөерләренә дә бәрә. Марат кызын сәламәтләндерер өчен бик тырыша. Баласына кайчан ярдәм кирәк – шул вакытта машинасына утырта да табибларга алып чыгып китә. Шөкер, кызы савыга. Инде 25 яше тулган. Үз гаиләсе белән Чаллыда яши. Ире белән ике бала үстерәләр икән. Улына 19 яшь тулган. Әнисенең гамәлләреннән соң ул хатын-кызлар белән сөйләшә дә алмаган. Янына әбисеннән башка кешене якын да китермәгән. Әкренләп аның да йөрәк яралары төзәлә икән инде.

– Тормышыма бер дә үкенмим. Дөрес, бик авыр чаклар булды. Бар назымны биргән, аның өчен үләргә әзер булган хатынымның хыянәте көчле итте мине. Балаларым хакына тормышның якасына ябышып яшәргә өйрәндем. Шигырьләр, хикәяләр язам. Интернетта язылучыларым белән аралашам. Дөньям түгәрәк, дусларым күп. Иң зур бәхетем – балаларым. Шөкер, аларны аякка бастырдым, оныкларым бар, шатланып туя алмыйм, – ди Марат. – Кайберәүләр бала үстерү бәхетеннән дә мәхрүм бит. Әчеп, мескенләнеп йөрүчесе, торыр урыны булмаганнар күпме! Гаиләкормаганнар... Гаиләсе булып та кадерен белмәгәннәр бар. Мин алардан өстен әле. Шуңа бик сөенәм.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

РӨСТӘМ ЗАКИРОВ:
«КАРГА САНДУГАЧ БУЛА АЛМЫЙ»

Җырчыны иң куандырган нәрсә – алкышлар. Татарстанның халык артисты Рөстәм ЗАКИРОВ иҗатына быел 30 ел. «Беркайчан да акча эшләүне беренче урынга куймадым», – ди ул. 84 яшенә кадәр мал асраган әнисе, кәеф күтәрә торган сәбәпләр, акчага корылган эстрада һәм улына биргән киңәшләре – безнең әңгәмә әнә шулар турында.



«Әнинең яраннары – әле дә өй түрендә»

:: Рөстәм абый, бәхетле кеше сез – 56 яшькә кадәр әни җылысын тоеп яшәгәнсез. Урыны җәннәттә булсын... Разыя апа нинди кеше иде?

– Безнең әни эшкә батыр, физик яктан көчле, җор телле кеше иде. 84 яшенә кадәр икешәр үгез, тана асрады. Әле мин мәҗбүриләмәсәм, аларын да бетерәсе түгел иде. Әтинең әнигә гел сүгенүенең сәбәбен эти мәрхүм булгач кына аңладым *(көлә)*. Баш бирә торган хатын булмаган ул! Кер юу машинасы да алдыртмады бит әни: агартмый, дип, элеккесе белән юды. Караңгы төнгә кадәр мәктәптә булса да (гомере буе җыештыручы булып эшләде ул), өйдәге дүрт ир-атны карарга өлгерде. Анда һәрвакыт акча була торган иде. Кулына керсә, тота белде, кирәкмәгәнне алмады – булганын кадерләде. Безне дә шуңа өйрәтте. Әни итәгендә иркәләнеп утырганны хәтерләмим. Кочаклап, сөеп утырырга вакыты да булмагандыр инде. Шөкер, иртә саен шалтыратып, хәлен белеп тордым. Бер көн шалтыратмасам яки бер атна кайтмый торсам, күршеләрне аякка бастырып эзләтә иде.

2019 елдан бирле әнине абыем белән киленебез үзләрендә – Мәтәскәдә тәрбияләп торды. Хәле авыраеп, хәтере китә башлаган иде. Аларга бик рәхмәтле без. Киленебез – Лилия Әхәтовна эшен ташлап, әнине бик яхшылап карады. Аллаһы Тәгалә гомерен дә кызганмады – 92сен тутырып китте. Әнинең яратып үстергән яраннары бар иде. Әле дә өй түрендә алар. Сулар сибеп, туфрагын алыштырып торабыз. Истәлек...

:: Сез кемгә күбрәк охшаган?

– Тән төзелеше, йөз-кыяфәт ягыннан әнигә тартымрак. Гаделлек буенча – этигә. Эти бик гадел кеше иде безнең. Ә болай, әни ягы да, эти ягы да бар.

:: Хәзер авылга еш кайтасызмы?

– Әйе. Авылны яратам мин. Газны өзмәдек, бакчасын ташламадык. Җәйләрен гел шунда инде.

:: Телефоннан сөйләшкәндә, «Быел бәрәңге уңышы яхшы – кәефләр шәп», – дидегез. Сезнең кәефне тагынниләр күтәрә ала?

– Дусларым арасында яхшы, гадел кешеләр булу шатландыра мине. 2008 елдан бирле «Toyota Corolla» машинасында йөрим. Пробегы 500 меңнән артып китте инде. Ләкин ничә елдан бирле яңа машина алып булмаганга көенмим мин, бүгенгәчә аның йөреп торуына сөенәм. Гаиләмнең уңышлары өчен сөенәм, таза-сау булганыбызга шатланам.

> Җырчыны иң шатландырган нәрсә – алкышлар. Иҗат итә башлаганнан бирле акчасына кызыкмадым, тамашачының мәхәббәте, хөрмәте хакына тырыштым.

«Сандугач ротациядә булмаса да, аны тыңлыйсы килә»

:: Соңгы берничә елда сәхнәгә сагындырып кына чыгасыз.

– Төрле чаклар була инде, сеңлем. Кайвакыт махсус югалып торам. Уйланып, бераз төшенкелеккә бирелгән вакытлар булгандыр. Мин үз-үзем белән сөйләшергә, фикерләшергә яратам. Яхшы кеше белән сөйләшәсе килә бит *(көлә)*. Шулай уйлана торгач, бер нәтиҗәгә килдем. Мине Ходай Тәгалә җырчы итеп яраткан. Мин бу миссияне үтәргә, халыкка хезмәт итәргә тиеш. Быел иҗатыма 30 ел була. Шул уңайдан 30 ноябрьдә Казанның «Чулпан» мәдәният үзәгендә концерт куябыз. Быел бөтен нәрсә «30» санына бәйле әле: бәрәңгене дә 30 сумнан саттык *(көлә)*.

Соңгы арада тән белән рухны да кайгырта башладым. 60ка якынайганда, аңгыраеп йөреп булмас, мин әйтәм... 1 июльдән велосипедта йөри башладым, спорт белән шөгыльләнәм, начар гадәтләрне бетерергә тырышам. Алланың рәхмәте белән, көн саен догалар укыйм. Аның икеләтә файдасын күрәм мин. Беренчедән, сүрәләр өйрәнәм. Икенчедән, татар сүзләрендә «ә», «ө», «ү» авазларын әйтү уңайсызрак, ә догаларда алар еш очрый, тавышны чыныктыра, ул яктан да камилләшәм.

:: 30 ел элек эстрада, музыка сәнгате бөтенләй башка төрле булгандыр. Бүген – күп нәрсә, хәтта эстрада да акчага корылган заманда – халыкның зәвыгын арттыру, аны ияртү авырмы?

– Халыкны ияләндереп була ул. Чәчәк бер көн су сибеп кенә үсми бит. Бу очракта да дөрес юнәлеш бирергә кирәк. Бүген күп кенә радиолар ротациягә акча түләгән җырчылар, җырлар белән мавыга.

> Ул акча эшләү урыны булырга тиеш түгел. Халык җырларын, классик җырларны җиренә җиткереп башкаручыларга аерым игътибар бирергә кирәк. Карганы еллар буе ротациягә бир – ул сандугач була алмый. Ә сандугачны ротациядә булмаса да тыңлыйсы килә.

«Бәрәңге алырга алып кайтсаң, шундук тынычлана алар»

:: Балаларыгыз да сезнең сукмактан атлый. Бигрәк тә Айрат саксофоны белән шактый танылырга өлгерде. Аның эстрадада кайнавын ничек кабул итәсез?

– Кайбер җырчылар әйтәләр бит әле, имеш, хезмәтебез авыр, балаларыбызга бу юлдан китәргә рөхсәт итмибез. Мин үзем – җырчы булып бәхетле булган кеше. Бу юлны сайлавыма шатланып туя алмыйм. Шулай

Блиц-сораштыру

– Тормыштан канәгатьме сез?
– Канәгать. Үз юлым, үз фикерем, үз тыңлаучым, мине хөрмәт иткән кешеләр бар. Мине яратмаучылар да бар. Булсын, мин дә бөтен кешене яратмыйм. Тормыш рәхәт, илләр генә тыныч булсын.

– Үкенечегез бармы?
– Тиешенчә, югары биеклектә башкара алмаган җырлар бар. Бәлки, музыкаль белем җитеп бетмидер. Бәлки, Ходай миңа шуннан артыгын язмагандыр.

– Авылдагы төп нигезгә кайтып яшәү теләге юкмы?
– Мин анда яшәгән шикелле инде болай да. Казан да, авыл да – үземнеке. Авылда яшәмәсәм дә, кайберәүләргә караганда авылга файдам күбрәк тиядер әле. Өч Пошалым да якын миңа, авылдашлар өчен дә чит кеше түгелмен.

– Бүген кешегә ни җитми?
– Бүген күпләр, әрсез булсам, бәхетле булам дип уйлый. Тыйнаклык җитми. Бәреп керсәм, барына да ирешәм, дигән караш бар. Ә син бәреп керерлек дәрәҗәгә җиткәнме соң әле? Анысын уйлап тору юк.

булгач, балаларымны ничек хупламыйм ди?

Яшерен-батырын түгел, Айратның башы әйләнгән чаклары булды. Үзем белән мәҗлесләргә йөртә башлагач, иң беренче булып Рифат Зарипов күреп алды аны. Командасына чакырды. Айратның 17–18 яшьлек чагы, аны-моны уйлап тормый. Ә минем төп бурыч – аны укытып чыгару. Концертлар күп түгел, укуны калдырмыйм, дия-дия, октябрьдә – 20, ноябрьдә 25 концерт куйгач, декабрьнең 20ләрендә күземә карый алмый башлады. Ләкин ул чакта да, өйдәгеләр акыл сата, урамдагылар дөрес сөйли, дигән фикере бетмәгән иде әле. Армиядән кайткач та, берничә җырчы белән эшләп карады. Кайберләре белән килешү төзегәнче, кемнең кем икәнен аңлатып карадым. Елмаеп кына куйды, янәсе, син каян беләсең инде аны. Нәтиҗәдә хаклы булуымны тиз аңлады.

:: Аның үзенә генә хас стиле бар. Шактый консерватив карашлы Рөстәм Закировка ошыймы ул?
– Кабул итү авыр булды. Мин аңа гел әйттем һәм әле дә шуны тукыйм: «Уйнавың беренче урында булсын, белемле музыкант икәнеңне онытма», – дим. Кыланмышлары матур, ләкин училище бетергән музыкантның репертуары затлы, сыйфатлы булырга тиеш. Аңа таләп зур. «Малаең бигрәк каты сикерә, ничек кулда тотасың аны?» – дип сорыйлар кайчак. Бәрәңге алырга алып кайтсаң, шундук тынычлана алар, дим.

:: Кызыгызга карата да шулай таләпчәнме сез?
– Әйе. 17 яшендә беренче җырын яздырды – моңа бик сөендем. Мактап та алам, кирәк чакта, киңәшен дә бирәм. Ләкин аңа да шул ук таләпләр: эшне җиренә җиткереп башкарырга, сыйфатны беренче урынга куярга.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

< Дәвамы. Башы 15, 22, 29 сентябрь саннарында

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА

ШУНДЫЙ ИНДЕ БЕЗ...

(Бәян)

Ике дистә ел эчендә Сыер авылының эче-тышы үзгәрсә дә, егет адашмас, туп-туры Шәкүрә карчыкларга барып төртелер, чөнки ул Айлиянең туган йорты иде. Ә бит адашырга да мөмкин иде. Авыл кырау суккан төсле шиңгән, бакчаларда былтыргы кипкән алабута тырпаешкан (бәрәңге чәчмиләр!), кайбер хуҗасыз ызбалар, ишелеп, борыны белән җиргә кадалган, урам гөрләтеп балалар уйнамый, тирә-якта үле тынлык иде. Орыс капкалы йортның да килеш-килбәте ямьсез: түбәсенең буялган калаен кояш «ашаган», ян бакчаның рәшәткәләре сынган, тәрәзәләр умыртка баганасы кәкрәйгән сыман кыйшайган иде. Мирзам, туктап, тирән генә сулады. Менә хәзер Айлия белән күрешә... Акыл, ярдәм ит! Хис өермәсен тузгыт, тузгыт! Егетнең максаты – пар эзләү...

Ишегалдында бер карчык ипи турап чебешләр ашата иде. Егет:

– Саумы сез? – диде. – Шәкүрә әби өйдәме?

«Аһ, Мирзам, Мирзам! Үзеңне ничек җиңел генә сатасың икән!» – дип ачынды егет. Әнә Ак мыек шаккатып тел шартлатты:

– Кичә генә айдан мәтәлдеңме әллә, культурный иптәш? Телевизор карамыйсың, гәзит укымыйсың, ахрысы. Миеңә тукы, Рудиядә туксан тугыз партия теркәлгән, безнеке – иң абруйлысы! Без – Зизанский бүлекчәсе. Төп офис – Москитта! Ну, басасыңмы безнең сафларга? Иртәгә үк таныклык тапшырабыз.

– Рәхмәт, Әмирҗан абзый. Зинһар, кыстама. Зизанскийга миннән күптин-күп, чуктин-чук сәлам!

– Синнән сәлам?! Син кем соң әле шулхәтле, хәчтерүш! Кит, артымнан иярмә!

– Кыстамагыз да! Бармыйм сайлауга! Туйдырдыгыз, кыручлар. – Карчык итәгендәге ярмасын җиргә какты. – Как сайлау җитә – боларга минем тавыш кирәк! Бая гына узышлый Әмирҗан, безнекен – «Кам-камнар»ны хупла, ди. Кичәгенәк «Алма» белән «Кишер»ләр йөрде. Син кайсы әртил тарафдары инде, сансыз?

– Мин сине беркая да өндәмим, Шәкүрә әби.

– Ыһы, җайлап-майлап кына үзеңә авыштырасыңмы? Капчыгыңа нибуч кибеттә сатылмыйча яткан кәнфит-прәнник тутыргансыңдыр. Теге сайлауларда тараткан чәегез искергән, тирес тәме килә иде, кыручлар! Гел аддуда эшегез.

Егет җилкәсендәге сумкасын сап-сары итеп юылган баскычка шудырды.

– Мине сезнең авылга – клубка эшкә җибәрделәр, Шәкүрә әби. Хор җитәкчесе мин. Фатирга кертәсеңме? – дип, Мирзам күрешергә дип кулын сузды. Карчыкның усал йөзе язылды, ул аяк астында буталган чебиләрне учын шапылдата-шапылдата ояларына табан кугач, егетне кочаклап ук алды.

– И-и, кертмәгән кая! Ялгыз башыма бик күңелсез, улым!

«Ялгыз башыма?» Тыю-тыелуларга карамыйча күңел учагында янган хис ялкынына бозлы су бөркеделәрмени, Мирзам бөреште. Айлия кайда соң? Җирдәгеләр әйтмешли, аның «бәгырь кисәге» кайда? Егет беләзегендәге ак боҗра тишегенә җиңелчә генә басып, Айлия турында белешер иде дә, Остаз бу супер төймәчекне сүндертте шул. Җирдәгеләр белән йөрәгең аша гына аралаш, приборларга таянма, диде. Әйдә, Мирзам йөрәге ни кушса, шуны эшләсен, ди. Әнә ул Айлия дип тибә! Тизрәк эзләп тап, ди! Юк, синең бурычың бүтән, узынма, дип бармак яный акыл. Нинди каршылык!

Ызбада берни дә үзгәрмәгән, еллар вакыт дигән узгынчыны мичкә дә кагылдырмаган, ул элеккеге кебек ап-ак кершән ягынып такта белән бүленгән ике бүлмә уртасында «утыра» иде. Карчык зәңгәрсу яулыгын артка чөеп бәйләгәч:

– Бисмилла, – дип, эләктергеч белән мичтән чуен тартып чыгарды. – Берсәк суынсын! Иртүк ике-өч кенә пүлән ягып, өйрә ашы куйганыем. Син, улым, иң соңгы бүлемтектә яшәрсең, урын-җир чиста, чирканма. Әбекәең сине хәзер пич ашы белән сыйлый.

Егет эчкә узды. Өмет белән узды. Анда Айлия көтә сыман иде. Караваттагы ап-ак кар түмәре кебек ике мендәр аның белән бергә көрсенде: юк, юк һәм тагын бер тапкыр юк!

– Улым, кем атлы әле үзең?

Олы якта табак-савыт шалтырады. Кемгә – нәрсә, кәҗәгә – кәбестә, ди татай (Мирзамның хәтерендә әллә нинди хикмәтле әйтемнәр саклана иде), хуҗабикәдә кунакны ашату кайгысы.

– Илдус мин, Шәкүрә әби, Илдус!

– Үзебезчә икән, чын татайча икән. Иту хәзерге яшьләр, очынып, нарасыйларын ничек кенә атамый. Безнекеләрнең әнә берсендә Изүлдә, икенчесендә Маргарит. Адәм көлкесе. Имеш, кайсыдыр илдә Маргарит Титчәр дигән яман данлыклы патшабикә җитәкче, ди. Булмагае ни! Аның татайга ни катнашы бар!

Изольдә белән Маргарет кемнең балалары икән соң? Айлиянекеме? Абыйсы Сәлимнекеме?

Өйрә ашы телеңне йотарлык, тәмле иде. Зур кашык белән аны тиешле җиренә бик тиз «озатты» егет. Тамагы туйгач, ул:

– Фатир бәясен сөйләшик, Шәкүрә әби, – диде.

– Әй, улым, ялгызлыкка бәя юк ла. Син лутчы Үзәк базарыннан онын-ярмасын, бәрәңгесен-кишерен апкайт. Түләү шул сиңа. – Карчык дивардагы «күке»ле сәгатькә чекрәйде. – Егерме минуттан ике туламы? Шафур Кафил атнакич базар урый. Авылдагы карт-корыга кирәк-ярагын апкайта. Улым, җәлт кенә җыен да тукталышка чап! Кафил шуннан ала баручы кешеләрне.

Дәвамы бар >

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм һөнәри эшчәнлектәге казанышлары өчен хезмәт ветераны **Закирҗанова** Гөлсинә Данан кызы, хезмәт ветераны **Сафина** Әнисә Рәхмәтулла кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе җинаятьчеләрне эзләү бүлегенең урлау һәм талау җинаятьләрен ачу бүлекчәсе башлыгы, полиция майоры **Закиров** Рөстәм Зөфәр улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе 12 номерлы «Гвардия» полиция бүлеге башлыгы, полиция полковнигы **Камалиев** Ирек Камил улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция участок уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәләренең эшчәнлеген оештыру идарәсе башлыгы, полиция полковнигы **Фәтхуллин** Марат Наил улына **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Морзалар урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Бәдертдинов** Рифат Әкрәметдин улына, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мөслим гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең биология укытучысы **Бариева** Ләйсән Фәһәметдин кызына, Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 62 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең информатика укытучысы **Беспалова** Татьяна Николаевнага, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районының «Балык Бистәсенең 2 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең тормыш иминлеге нигезләре укытучысы **Гобәйдуллин** Рөстәм Камил улына, «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең программалар һәм проектларны гамәлгә ашыру үзәге директоры **Зыяева** Гөлмирә Акмал кызына, «Ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Минзәлә мәктәп-интернаты» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе укытучы-дефектологы **Ищерякова** Валентина Васильевнага, Казан шәһәре Совет районының «Татар телендә белем бирелә торган 149 номерлы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган тел һәм әдәбият укытучысы **Кәлимуллина** Рәзинә Шәйдулла кызына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Түбән Уратма урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Мохлисов** Исхак Фәйзрахман улына, Казан шәһәре Вахитов районының «Һади Такташ исемендәге татар телендә белем бирелә торган 27 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган (татар) тел һәм әдәбият укытучысы **Нурмиева** Гөлгенә Вазыйх кызына, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «10 номерлы күппрофильле лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең биология укытучысы **Салихова** Резида Рәсим кызына, Казан шәһәре Совет районының «125 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Хәбибуллина** Ирина Николаевнага, Казан шәһәре Яңа Савин районының «146 номерлы «Ресурс» лицее» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Хлебникова** Нина Николаевнага, Чаллы шәһәренең «2 номерлы балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесенең рәсем укытучысы **Шәрәфетдинова** Гүзәл Таһир кызына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең физик культура укытучысы **Ендиряков** Александр Владимировичка, Казан шәһәре Вахитов районының «41 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теленә өйрәтүче тәрбиячесе **Лотфуллина** Айсылу Газинур кызына, Казан шәһәре Киров районының «101 номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тәрбиячесе **Токмакова** Юлия Анатольевнага, Казан шәһәре Яңа Савин районының «Татар телендә белем бирелә торган 13 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган (татар) тел һәм туган (татар) әдәбият укытучысы **Шәгәрәева** Алинә Илсур кызына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

АТНА САЕН БЕР БҮЛӘК

ЯЗЫЛ!
2024 елның беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына язып

2–12 октябрь –
ташламалы бәядән язылу көннәре

П2435 (җомга) >> ~~571 сум 98 тиен~~ **497 сум 34 тиен**

П2409 (сиш., пәрш., җомга) >> ~~1255 сум 86 тиен~~ **1086 сум 18 тиен**

КВИТАНЦИЯНЕ БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт

БҮЛӘК ОТ!
Атна саен бер приз иясе ачыклана.
Беренче атна бүләге –
ЭЛЕКТР ЧӘЙНЕГЕ
12 октябрьдә уйнатыла

ҖИҢҮЧЕ БУЛ!

Акциядә катнашучыларны гыйнвар аенда тагын да зуррак бүләкләр көтә

- ТУЗАН СУЫРТКЫЧ
- КЫСКА ДУЛКЫНЛЫ МИЧ
- ИТТАРТКЫЧ
- МУЛЬТИПЕКАРЬ
- ҮТҮК

Тулырак сайтта: vatantat.ru
Акция 2023 елның 29 сентябреннән башлап 2024 елның 10 февраленә кадәр дәвам итәчәк.
Акциянең оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Реклама 16+

Әз-мәз мәзәк

Чәчтарашның: «Ну, ничек, ошый-мы?» – дигән соравына «Юк», – дип җавап бирсәң, чәчеңне кире ябышты-ра микән?

* * *

– Помидор трактордан нәрсәсе белән аерыла?
– Помидор кызыл, ә тракторның ишекләре тышка таба ачыла.

* * *

– Әгәр мин сине хәтерлим икән, димәк, гафу итмәгәнмен.

* * *

– Бүген өйгә төнге бердә генә кайттым.
– Ә хатының нәрсә диде?
– Мин әле өйләнмәгән.
– Алайса, ник алай иртә кайттың?

* * *

– Лилия, 10 минутлык доклад әзер-ләргә куштым бит! Ник ярты сә-гатьлек итеп яздың?
– Гали Вәлиеч, мин ул докладны өч нөсхәдә чыгарган идем, бер текстны өч тапкыр укыдыгыз.

* * *

– Нишләп кошелегыңны баш астыңа салып йоклыйсың?
– Бу – минем финанс мендәрем.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде



Беләсең килсә...

1 «Кукрыниксы» тәхәллүсе белән кем иҗат иткән?
а) язучылар төркеме;
б) рәссамнар төркеме;
в) җырчылар төркеме.

2 Илнар хәзрәт Зиннәтуллин исемен нинди исемгә алыштырды?
а) Нариман;
б) Нурулла;
в) Нәфигулла.

3 Сода формуласы:
а) $NaCl$;
б) $NaHCO_3$;
в) $NaOH$.

Җаваплар: 1.б); 2.б); 3.б).

Сканворд җаваплары

Горизонталь: иләк, чигә, гарип, Лия, үгез, кием, рам, ике, хаҗ, рок, Лепс, ар, лыгыр, Си, Замирә, Апас, сим, Сак, ут, укчы, кырт, Ира, ул, Ик, Ык, чак, лаек, ыру, ГУЛАГ, Райкин, урак, Азалия, мат.

Вертикаль: изу, укучы, Албастылар, Ра, Әгерже, ми, кура, каза, Плимут, АКМ, Мисыр, чик, гәрчә, кат, ипи, Илгиз, рас, Каунас, Әлмира, пари, ел, корсак, Рыкалин, иялек, ис, вак.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының уртак каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 13580 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 337

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+